МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.12.2023 № 580-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 12 февралендәге 92-осн номерлы боерыгы белән расланган Чирмешән урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Урман кодексының 83 статьясының 1 өлешендәге 9 пункты, «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 3 өлешендәге 1 пункты нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Чирмешән урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентын раслау турында» 2019 елның 12 февралендәге 92-осн номерлы боерыгы (16.04.2020 №313-осн, 02.12.2020 №838-осн, 17.01.2022 №26-оснбоерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Чирмешән урманчылыгының урман хуҗалыгы регламентына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары И.Н.Зариповка йөкләргә.

Министр Р.Ә.
Кузюров

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлыгының
2019 елның 12 февралендәге 92-осн
номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Урман
хуҗалыгы министрлыгының 2023
елның 11 декабрендәге 580-осн
номерлы боерыгы редакциясендә)

# ЧИРМЕШӘН УРМАНЧЫЛЫГЫНЫҢ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ РЕГЛАМЕНТЫ

(2023 елның 1 гыйнварына булган торышында)

**Казан шәһәре - 2023**

Эчтәлек

КЕРЕШ ........ 7
1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР ........ 19
1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама ........ 19
1.1.1. Урманчылык һәм урнашкан урыны ........ 19
1.1.2. Урманчылыкның, кишәрлек урманчылыкларының гомуми мәйданы, урманчылык территориясенең районнар буенча бүленеше ........ 19
1.1.3. Урманнарны урман үсү зоналарына, урманлы районнарга һәм урманнарны саклау һәм урман орлыкчылыгы районнарына бүлү ........ 21
1.1.4. Урманчылык урманнарының кварталлар яисә аларның өлешләре буенча максатчан билгеләнеше һәм саклагыч урман категорияләре буенча бүленеше, шулай ук саклагыч, эксплуатация һәм резерв урманнарын бүлеп чыгару нигезләре ........ 23
1.1.5. Урманчылык территориясендә урман фонды җирләре составыннан урманлы һәм урмансыз җирләргә сыйфатлама ........ 25
1.1.6. Гамәлдәге һәм проектлана торган махсус сакланыла торган табигать территорияләренә һәм объектларга, аларны оештыру, экологик челтәрләрен үстерү, биотөрлелеген саклау планнарына сыйфатлама ........ 26
1.1.7. Илкүләм мирас буенча проектлана торган урманнарга сыйфатлама ........ 26
1.1.8. Диләнке эшләрен гамәлгә ашырганда сакланырга тиешле биологик күптөрлелек төрләрен һәм буфер зоналары зурлыклары исемлеге ........ 26
1.1.9. Гамәлдәге урман, урман эшкәртү инфраструктурасы объектларына, урман инфраструктурасы ясауга бәйле булмаган объектларга, әлеге объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү чараларына территориаль планлаштыру документларында каралган сыйфатлама ........ 31
1.2. Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре ........ 34
2 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН РӨХСӘТЛЕ ФАЙДАЛАНУ НОРМАТИВЛАРЫ, ПАРАМЕТРЛАРЫ ҺӘМ ЧОРЛАРЫ, УРМАННАРНЫ САКЛАУ ҺӘМ ЯҢАДАН ҮРЧЕТҮ НОРМАТИВЛАРЫ ........ 38
2.1. Урманнардан агач материалы әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 38
2.1.1. Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кисү буенча файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләме ........ 39
2.1.2. Урманнарны тәрбияләгәндә урта яшьле, өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кисү буенча файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләме (агач материалы алуның ел саен рөхсәт ителгән күләме) ........ 49
2.1.3. Барлык төр кисүләрдә файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләме (агач материалы алуның ел саен рөхсәт ителгән күләме) ........ 77
2.1.4. Кисентеләрнең яше ........ 81
2.1.5. Агачлыкларның тулылыгын һәм составын, диләнкеләрнең күләмнәрен, диләнкеләрнең тоташу чорларын, киртекләр санын, кисүләрнең кабатлану чорларын исәпкә алып, агач материалын сайлау проценты (ешлыгы) ........ 82
2.1.6. Урманнарны торгызу алымнары ........ 84

2.1.7. Урманнардан агач материалы әзерләү өчен файдалану вакытлары һәм башка мәгълүматлар ........ 85
2.2. Урманнардан чәер әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 86
2.3. Урманнардан агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 88
2.3.1. Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын төрләре буенча әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары (ел саен рөхсәт ителгән күләмнәре) һәм параметрлары ........ 89
2.3.2. Урманнардан агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыю өчен файдалану чорлары ........ 89
2.4. Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 89
2.4.1. Урманнардан азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен төрләре буенча әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары (ел саен рөхсәт ителгән күләмнәре) һәм параметрлары ........ 90
2.4.2. Әзерләү һәм җыеп алу вакытлары ........ 91
2.4.3. Агач сутлары әзерләгәндә нормативлар һәм параметрлар ........ 91
2.4.4. Абага-кара абага әзерләү ........ 92
2.4.5. Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен файдалану чорлары ........ 92
2.5. Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 93
2.5.1. Аучылык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен рөхсәт ителгән биотехник чаралар уздыру исемлеге һәм нормалары ........ 93
2.6. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 94
2.6.1. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану параметрлары ........ 95
2.7. Балыкчылыкны гамәлгә ашыру, һәвәскәрләрчә балык тотудан тыш ........ 95
2.8. Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген һәм мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 95
2.9. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 96
2.9.1. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары ........ 96
2.9.2. Рекреация эшчәнлегенә бәйле зона кварталларының һәм (яки) аларның өлешләре исемлеге ........ 96
2.9.3. Рекреация эшчәнлегенә караган зона территориясен функциональ зоналарга бүлү ........ 96
2.9.4. Урман кишәрлекләрендә вакытлыча төзелгән корылмалар исемлеге һәм аларны төзекләндерү нормативлары ........ 97
2.9.5. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану параметрлары һәм чорлары ........ 97

2.10. Урманнардан урман плантацияләре ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ............................................... 98
2.11. Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен һәм дару үләннәрен үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары98
2.12. Урманнардан урман питомниклары ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ............................................... 99
2.13. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары .......................................................................................... 100
2.14. Урманнардан сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портлары булдыру һәм аларны киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ............................................. 102
2.15. Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ............................................. 103
2.16. Урманнардан урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ....... 106
2.17. Урманнардан дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары .......................................................................................... 107
2.18. Урманнарны саклауга һәм яңадан үрчетүгә карата таләпләр ........................... 107
2.18.1. Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларына, урманнарны радиоактив матдәләр белән пычранудан һәм тискәре башка йогынтыдан саклауга карата таләпләр ................................................................................................................................ 107
2.18.2. Урманнарны саклауга карата таләпләр (санитар-савыктыру чараларының, урманнарны саклау буенча профилактика чараларының, зарарлы организмнарның чыганакларын ликвидацияләү чараларының, шулай ук вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән башка чараларның нормативлары һәм параметрлары) ................................................................................................................................ 110
2.18.3. Урманнарны яңадан үрчетүгә карата таләпләр (урманнарны торгызу, урман үстерү, урманнарны карау чараларын үткәрү нормативлары, параметрлары, чорлары) ............................................................................................................................. 117
2.19. Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар буенча урманнардан файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре ............................................................................ 132
3 БҮЛЕК. Урманнардан файдалануда чикләүләр .................................................... 133
3.1. Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләүләр ...................... 133
3.2. Махсус саклана торган урман кишәрлекләренең төрләре буенча чикләүләр ............................................................................................................................ 135
3.3. Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр ........................................... 137

# КЕРЕШ

Әлеге урман хуҗалыгы регламенты Чирмешән урманчылыгы чикләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау һәм торгызу нигезе булып тора.

Урман хуҗалыгы регламенты Россия Федерациясе Урман кодексының 87 статьясының 7 өлеше, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдә булу срокларын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 февралендәге 72 номерлы боерыгы нигезендә әзерләнде.

Урман хуҗалыгы регламентының гамәлдә булу чоры – 2029 елның 1 апреленә кадәр.

Урман хуҗалыгы регламентын эшләгәндә дәүләт урман реестры материаллары файдаланылды.

Регламентны эшләүчеләр:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы

Почта адресы: Ямашев проспекты, 37А йорт, Казан шәһәре, 420124.

E-mail: Minleshoz@tatar.ru.

Сайт: Minleshoz.tatarstan.ru.

Тел. (843) 221-37-01.

Факс (843) 221-37-37.

## Россия Федерациясенең закон актлары

Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – РФ Урман кодексы).

Россия Федерациясе Су кодексы (алга таба – РФ Су кодексы).

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы).

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ Гражданлык кодексы).

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Янгын куркынычсызлыгы турында» ФЗ).

«Махсус сакланыла торган табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 33-ФЗ номерлы федераль закон).

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 52-ФЗ номерлы федераль закон).

«Геодезия, картография һәм киңлек мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге 431-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 431-ФЗ номерлы федераль закон).

«Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән имин эш итү турында» 1997 елның 19 июлендәге 109-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 109-ФЗ номерлы федераль закон).

«Намус иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 125-ФЗ номерлы федераль закон).

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 221-ФЗ номерлы федераль закон).

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 69-ФЗ номерлы федераль закон).

«Җир корылышы турында» 2001 елның 18 июнендәге 78-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 78-ФЗ номерлы федераль закон).

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 7-ФЗ номерлы федераль закон).

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 35-ФЗ номерлы федераль закон).

«Элемтә турында» 2003 елның 07 июлендәге 126-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 126-ФЗ номерлы федераль закон).

«Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 04 декабрендәге 201-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 201-ФЗ номерлы федераль закон).

«Орлыкчылык турында» 2021 елның 30 декабрендәге 454-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 454-ФЗ номерлы федераль закон).

«Ау һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы федераль закон).

«Үсемлекләр карантины турында» 2014 елның 21 июлендәге 206-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 206-ФЗ номерлы федераль закон).

«Җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 172-ФЗ номерлы федераль закон).

## РФ Урман кодексында каралган хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актлар (2023 елның 01 гыйнварына)

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары** | | |
| 91 статьяның 7 өлеше | Дәүләт реестрыннан өземтәләр биргән өчен түләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр биргән өчен түләү күләме һәм аны алу тәртибе турында» 2007 елның 3 мартындагы 138 номерлы карары |
| 100 статья | Урманнарга һәм алардагы табигать объектларына китерелгән зыянны каплау | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга һәм аларда булган табигать объектларына |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карары |
| 96 статья | Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт урман контроле (күзәтчелеге) турында» 2021 елның 30 июнендәге 1098 номерлы карары |
| 50 статьяның 3 өлеше | Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле агач материалының максималь күләмен билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле агач материалының иң зур күләмен билгеләү турында» 2007 елның 22 июнендәге 395 номерлы карары |
| 73 статьяның 4 өлеше | Федераль мөлкәттәге урман ресурслары бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеген арендалау өчен урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль милектәге урман кишәрлеген түләүле нигездә файдалануга алу буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү дәрәҗәләре һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү дәрәҗәләре турында» 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары |
| 44 статья | Урманнардан сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портлары территорияләрен булдыру һәм киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су объектын файдалануга бирү турында карар әзерләү һәм кабул итү турында» 2022 елның 19 гыйнварындагы 18 номерлы карары |
| 45 статья | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе элемтә чыбыкларын һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 1995 елның 9 июнендәге 578 номерлы карары |
| 76 статьяның 3 өлеше | Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре буенча түләү. Федераль мөлкәттә, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары мөлкәтендә һәм муниципаль мөлкәттә торучы җирләрдә әзерләнә торган агач материалы берәмлеге өчен түләү ставкаларын билгеләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль милектәге урман кишәрлеген түләүле нигездә файдалануга алу буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү дәрәҗәләре һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү дәрәҗәләре турында» 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары |
| $23^1$ статьяның 3 өлеше, $60^3$ статья | Урманнарда санитар куркынычсызлык. Урман утыртмаларын кисү тәртибе | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда санитария куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 декабрендәге 2047 номерлы карары |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| $23^1$ статьяның 3 өлеше, 53 статья | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 7 октябрендәге 1614 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарны янгына каршы кору чаралары турында» 2011 елның 16 апрелендәге 281 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннары аркасында урманнарда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнары көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 1464 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында» 2011 елның 17 маендагы 376 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман янгыннарын сүндерү планын төзү һәм аны һәм аның рәвешен раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 17 маендагы 377 номерлы карары,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда һәм урман янгыннарында янгын куркынычы турындагы мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 18 августындагы 687 номерлы карары |
| 22 статьяның 3 өлеше | Урманнарны үзләштерү өлкәсендә инвестиция эшчәнлеге.<br>Урманнарны үзләштерү өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген әзерләү һәм раслау | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарны үзләштерү турында өстенлекле инвестиция проектлары турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану турында» 2018 елның 23 февралендәге 190 номерлы карары |
| 114 статьяның 6 өлеше | Урман паркы зоналарында урнашкан урманнарның функциональ зоналары | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 114 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән урманнар булган җирләрнең чикләрен үзгәртү һәм урман паркs зоналарында урнашкан урманнарда функциональ зоналарны билгеләү гагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 21 декабрендәге 1755 номерлы карары |
| 13 статья | Урман инфраструктурасы | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | урманнар, файдаланыла торган урманнар һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеген раслау турында» 2012 елның 17 июлендәге 1283-р номерлы күрсәтмәсе |
| 21 статья | Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урманнар, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар исемлеген раслау турында» 2022 елның 30 апрелендәге 1084-р номерлы күрсәтмәсе |
| 21[1] статья | Урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар төзү һәм эксплуатацияләү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Саклагыч урманнар, эксплуатация урманнары, резерв урманнары өчен урман инфраструктурасын булдыруга бәйле булмаган капиталь булмаган төзелмәләр, корылмалар төзү һәм эксплуатацияләү» 2022 елның 23 апрелендәге 999-р номерлы күрсәтмәсе |
| 45 статья | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының саклык зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары |
| 73[1] статьяның 6 өлеше | Дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү<br>Дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен әзерләү һәм төзү тәртибе | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Агач материалы әзерләү өчен дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзү хокукына конкурста катнашучыларның конкурс тәкъдимнәрен бәяләү кагыйдәләрен һәм тәкъдим ителгән шартларны бәяләү һәм агач материалы әзерләү өчен дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсен төзү хокукына конкурста җиңүчене билгеләүгә нигез булган билгеләрне раслау турында» 2019 елның 7 мартындагы 241 номерлы карары |
| **Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы (алга таба – Россия Табигать министрлыгы) норматив актлары** | | |
| 62 статьяның 7 өлеше | Урман торгызу. Урман торгызу кагыйдәләре | «Урманнарны торгызу кагыйдәләрен, урманнарны торгызу проектының формасын, составын, аны килештерү тәртибен, аны килештерүдән баш тарту нигезләрен, шулай ук урманнарны торгызу проектының электрон рәвештәге форматына карата таләпләр раслау турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1024 |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | номерлы боерык |
| $73^{1}$ статьясындагы 7 өлеше | Урман кишәрлегенең типик аренда шартнамәсе | «Урман кишәрлекләрен түләүле нигездә файдалануга тапшыруның бер төрле шартнамәләрен раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 542 номерлы боерык |
| 77 статьяның 7 өлеше | Урман утыртмаларын сату-алу турында типик шартнамә | «Урман утыртмаларын сату-алуның бер төрле шартнамәсен раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 488 номерлы боерык |
| $60^{15}$ статья | Сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләре | «Россия Федерациясе Кызыл китабына яисә Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән, сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 елның 29 маендагы 264 номерлы боерык |
| $23^{1}$ статьяның 3 өлеше, 64 статьяның 3 өлеше | Урманнарны тәрбия кылу. Урманнарны тәрбия кылу кагыйдәләре. Урман утыртмаларын кисү тәртибе | «Урманнарны карау кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 534 номерлы боерык |
| 112 статьяның 5 өлеше | Махсус саклanучы табигать территорияләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үрчетү үзенчәлекләре | «Махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үрчетү үзенчәлекләрен раслау турында» 2021 елның 12 августындагы 558 номерлы боерык |
| $53^{1}$ статья | Урман янгыннарын кисәтү | «Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары төрләрен, урманнардан файдаланучы затларның әлеге чаралар белән тәэмин ителү нормативларын, урманнардан файдаланганда булырга тиешле урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары нормаларын раслау турында» 2014 елның 28 мартындагы 161 номерлы боерык |
| $53^{1}$ статья | Урманнарда янгын чыгу куркынычын һәм урман янгыннарын мониторинглау | «Урманнарда янгын куркынычын һәм урман янгыннарын күзәтүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 23 июнендәге 276 номерлы боерык |
| 15 статьяның 3 өлеше | Урман үсә торган зоналар һәм урманлы районнар | «Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерык |
| 87 статьяның 7 өлеше | Урман хуҗалыгы регламентларының составы, аларны эшләү тәртибе, аларның гамәлдә булу вакыты һәм | «Урман хуҗалыгы регламентлары составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдә булу вакытын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | аларга үзгәрешләр кертү тәртибе | февралендәге 72 номерлы боерык |
| $60^{5}$ статья | Урман патологиясе буенча дәүләт мониторингы | «Урман авырулары буенча дәүләт мониторингын гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 апрелендәге 156 номерлы боерык |
| $60^{7}$ статья | Зарарлы организмнар таралуны кисәтү | «Зарарлы организмнар таралуны кисәтү чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 912 номерлы боерык |
| $60^{6}$ статьяның 4 өлеше | Урман патологиясе буенча тикшеренүләр. Урман патологиясе буенча тикшеренүләрне уздыру тәртибе | «Урман авыруларына бәйле тикшеренүләрне уздыру тәртибен һәм урман авыруларына бәйле тикшеренү актының рәвешен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 910 номерлы боерык |
| $23^{2}$ статьяның 10 өлеше, 29 статьяның 11 өлеше, $23^{1}$ статьяның 3 өлеше | Диләнке эшләре.<br>Агач материалы әзерләү.<br>Агач материалы әзерләү кагыйдәләре. Урман утыртмаларын кисү тәртибе | «Агач материалы әзерләү кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда агач материалы әзерләү үзенчәлекләрен раслау турында» 2020 елның 1 декабрендәге 993 номерлы боерык<br>«Диләнке эшләре төрләрен, аларны башкару тәртибен һәм эзлеклелеген, диләнке эшләренең технологик картасы формасын, урман бүлемтегеи актыккы тикшерү акты формасын һәм урман бүлемтеген актыккы карап чыгу тәртибен раслау турында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 23 номерлы боерык,<br>«Урман бүлемтегенең таксация тасвирламасына кертелә торган мәгълүматлар составын, урман бүлемтегенең таксация тасвирламасын төзү тәртибен, аның электрон форматындагы форматына карата таләпләрне, урман бүлемтегенең таксация тасвирламасының урман бүлемтегенең хакыйкый торышы турындагы мәгълүматка туры килмәвен билгеләү тәртибен, урман бүлемтегенең таксация тасвирламасы формасын раслау турында» 2022 елның 14 октябрендәге 687 номерлы боерык |
| $60^{4}$ статья | Урманнарны яклау буенча районнарга бүленеш | «Урманнарда җиңелчә, уртача һәм көчле урман патологиясе булган зоналарны билгеләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 гыйнварындагы 1 номерлы боерык |
| 91 статья | Дәүләт урман реестры | «Дәүләт урман реестрына документлаштырылган мәгълүматлар кертүгә һәм аны үзгәртүгә нигез булган |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | документларның исемлеген, аларның формаларын һәм аларны әзерләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 ноябрендәге 496 номерлы боерык, «Дәүләт урман реестрында булган, зарури тәртиптә бирелә торган мәгълүматлар төрләре исемлеген һәм аны бирү шартларын раслау турында» 2013 елның 30 октябрендәге 464 номерлы боерык, «Дәүләт урман реестрын алып бару формаларын раслау турында» 2021 елның 24 декабрендәге 1007 номерлы боерык |
| $70^{1}$ статьяның 12 өлеше | Урман кишәрлекләрен проектлау | «Урман кишәрлегенең проект документациясе составына һәм эчтәлегенә таләпләрне раслау турында» 2017 елның 3 февралендәге 54 номерлы боерык |
| $60^{13}$ статья | Урманнарны радиоактив пычранудан саклау үзенчәлекләре | «Урманнарның радиоактив пычрану зоналарында профилактика һәм тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 елның 8 июнендәге 283 номерлы боерык |
| 65 статьяның 5 өлеше | Урман орлыкчылыгы | «Урман орлыкчылыгы объектларын (урман орлыкчылыгы плантацияләрен, даими урман орлыклары кишәрлекләрен) төзү һәм аерып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 20 октябрендәге 438 номерлы боерык, «Урманның төп агач токымнарының үстерү районнарына бүленгән урман үсемлекләре орлыкларын куллану тәртибен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 909 номерлы боерык |
| 46 статьяның 4 өлеше | Урманнардан агач эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен файдалану | «Урманнардан агач эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 54 номерлы боерык |
| 38 статья | Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану | «Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә генә урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 2 июлендәге 408 номерлы боерык |
| 49 статьяның 4 өлеше | Урманнардан файдалану турында хисап. Урманнардан файдалану турында хисап тапшыру | «Урманнардан файдалану турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнардан файдалану турында хисап тапшыру формасын һәм тәртибен, шулай ук |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | тәртибе | урманнардан файдалану турында электрон рәвештә хисап формасына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 21 августындагы 451 номерлы боерык |
| 66 статьяның 2 өлеше | Урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерү турында хисап. Урманнардан файдалану һәм урман үстерү турында хисап тапшыру тәртибе | «Урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерү турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерү турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерү турында электрон рәвештәге хисап форматына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 21 августындагы 452 номерлы боерык |
| 89 статья | Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза. Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза тәртибе | «Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы һәм муниципаль экспертиза тәртибен раслау турында» 2020 елның 30 июлендәге 513 номерлы боерык |
| 26 статьяның 3 өлеше | Урман декларациясе. Урман декларациясен тутыру һәм тапшыру тәртибе | «Урман декларациясе формасын, аны тутыру һәм тапшыру тәртибен, электрон рәвештә урман декларациясе форматына таләпләр раслау турында» 2021 елның 29 апрелендәге 303 номерлы боерык |
| 60 статьяның 3 өлеше, $60^{11}$ статьяның 3 өлеше | Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап. Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап тапшыру тәртибе. | «Урманнарны янгыннардан саклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны янгыннардан саклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны янгыннардан саклау турында электрон рәвештә хисап тапшыру форматына карата таләпләр, урманнарны яклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны яклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны яклау турында электрон рәвештә хисап форматына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 09 мартындагы 78 номерлы боерык |
| $60^{8}$ статьяның 5 өлеше | Зыянлы организмнарның чыганакларын юк итү | «Зыянлы организмнарның чыганакларын юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 913 номерлы боерык |
| $53^{4}$ статья | Урман янгыннарын сүндерү | «Урман янгыннарын сүндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 1 апрелендәге 244 номерлы боерык |
| $98^{2}$ статья | Урман сагы | «Урман сагын гамәлгә ашыру тәртибен һәм нормативларын раслау турында» 2021 елның |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | 15 декабрендәге 955 номерлы боерык |
| 64[1] статьяның 2 өлеше | Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман урнашкан җирләргә кертү | Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман урнашкан җирләргә кертү тәртибен һәм тиешле акт рәвешләрен раслау турында» 2019 елның 11 мартындагы 150 номерлы боерыгы |
| 86 статьяның 5 өлеше | Россия Федерациясе субъектының урман планы. Россия Федерациясе субъектының урман планы составы һәм аны әзерләү тәртибе | «Россия Федерациясе субъекты урман планының бер төрле рәвешен һәм составын, аны әзерләү һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 декабрендәге 692 номерлы боерык |
| 32 статья | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | «Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу турында» 2020 елның 28 июлендәге 496 номерлы боерык |
| 67 статья, 68 статья | Урман корылышы турында гомуми нигезләмәләр Урман корылышының эчтәлеге | «Урман корылышы буенча файдалану күрсәтмәсен раслау турында» 2022 елның 5 августындагы 510 номерлы боерык |
| 63 статьяның 3 өлеше | Урман үстерү. Урман үстерү кагыйдәләре | «Урман үстерү кагыйдәләрен, урман үстерү проектының формасын, составын, аны килештерү тәртибен, аны килештерүдән баш тарту нигезләрен, шулай ук урман үстерү проектының электрон рәвештәге форматына карата таләпләр раслау турында» 2021 елның 20 декабрендәге  978 номерлы боерык |
| 88 статьяның 2 өлеше | Урманнарны үзләштерү проекты. | Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнарны үзләштерү проектының составын, аны эшләү һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибен, электрон документ рәвешендә урманнарны үзләштерү проекты форматына карата таләпләр раслау турында» 2021 елның 16 ноябрендәге 864 номерлы боерыгы |
| 39[1] статья | Урман питомникларын булдыру һәм аларны эксплуатацияләү | «Урман питомникларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 12 октябрендәге 737 номерлы боерык |
| 45 статья | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану | «Урманнардан линияле объектлар төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану кагыйдәләрен һәм, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә, урман кишәрлеген бирмичә урманнардан линияле объектлар төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 10 июлендәге 434 номерлы боерык |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 43 статья | Җир астын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре | «Урманнардан җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм, җир кишәрлеге бирмичә, сервитут билгеләп яки билгеләмичә, урманнардан җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару өчен файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 7 июлендәге 417 номерлы боерык |
| 31 статья | Чәер әзерләү | «Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 911 номерлы боерык |
| 38[1] статья | Урманнардан балыкчылыкны гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан балыкчылыкны гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 13 октябрендәге 742 номерлы боерык |
| 39 статья | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү | «Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 497 номерлы боерык |
| 34 статья | Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю | «Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 494 номерлы боерык |
| 40 статья | Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 487 номерлы боерык |
| 41 статья | Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану | «Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 908 номерлы боерык |
| **Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы (алга таба – Рослесхоз) норматив актлары** | | |
| 29 статьяның 6 өлеше | Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләмен исәпләп чыгару тәртибе | «Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләмен исәпләп чыгару тәртибен раслау турында» 2011 елның 27 маендагы 191 номерлы боерык<br>«Кисентеләрнең яшен билгеләү турында» 2015 елның 9 апрелендәге 105 номерлы боерык |
| 29 статьяның 7 өлеше, 81 статьяның 3 пункты | Агач материалы әзерләү. Агач материалын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеге | «Агач материалын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында» 2011 елның 5 декабрендәге 513 номерлы боерык |

| Россия Федерациясе Урман кодексы статьясы | Россия Федерациясе Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 53 статьяның 4 өлеше, 53[1] статья | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. Урман янгыннарын кисәтү | «Урманнарны янгынга каршы кору нормативларын раслау турында» 2012 елның 27 апрелендәге 174 номерлы боерык, «Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм, һава торышына карап, урманнарда табигый янгын куркынычы классификациясен раслау турында» 2011 елның 5 июлендәге 287 номерлы боерык |
| 65 статьяның 5 өлеше | Урман орлыкчылыгы | «Урман орлыкларын үстерү районнарын билгеләү турында» 2022 елның 19 декабрендәге 1032 номерлы боерык |
| **Россия Федерациясе субъекты норматив актлары** | | |
| 82, 83 статьялар | Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре.<br>Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының аерым вәкаләтләрен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшыру | «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,<br>Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге ПУ-880 номерлы Указы,<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 30 июлендәге 531 номерлы карары,<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының региональ яки муниципальара әһәмиятендәге гомуми файдалану автомобиль юллары исемлеген раслау турында» 2022 елның 13 октябрендәге 1099 номерлы карары |
| 82 статьяның 7 өлеше | Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларын билгеләү | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында гражданнарга үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләү ставкаларын билгеләү турында» 2020 елның 7 октябрендәге 107-2/нпс-2020 номерлы карары |

# 1 БҮЛЕК. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

## 1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама

### 1.1.1. Урманчылык һәм урнашкан урыны

Чирмешән урманчылыгы (алга таба – урманчылык) Татарстан Республикасының көньяк өлешендә Чирмешән районы территориясендә урнашкан.

Урманчылык конторасы Чирмешән авылы район үзәгендә, иң якын урнашкан Шантала тимер юл станциясеннән 25 километр (алга таба – км) ераклыкта һәм Татарстан Республикасы башкаласы Казаннан 235 км ераклыкта урнашкан.

Урманчылыкның почта адресы: 423100, Татарстан Республикасы, Чирмешән авылы, Техник урамы, 18 йорт, тел.: 8 (84396) 2-58-79.

E-mail: Cheremshanskoe.Gku@tatar.ru.

Урманчылык территориясенең төньяктан көньякка таба озынлыгы – 40 км, көнчыгыштан көнбатышка таба – 58 км.

### 1.1.2. Урманчылыкның, кишәрлек урманчылыкларының гомуми мәйданы, урманчылык территориясенең районнар буенча бүленеше

Урманчылык территориясенең муниципаль берәмлекләр буенча бүленеше 1 нче таблицада китерелә.

1 нче таблица

Урманчылыкның төзелеше

| Т/с | Урманчылык | Кишәрлек урманчылык-лары | Урман кв. № | Административ район (муниципаль берәмлек) | Мәйданы, гектар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | Чирмешән | Казанка | 1-81 | Чирмешән | 10325 |
| 2 | | Светлогорск | 1-92 | Чирмешән | 13162 |
| 3 | | Чишмә икенче | 1-138 | Чирмешән | 13048 |
| Урманчылык буенча барлыгы | | | | | 36535 |

Урманчылыкның урман фонды дүрт зур урман кишәрлегеннән тора, һәм төньяктан – Аксубай һәм Кәләй урманчылыклары, көнчыгыштан – Лениногорск урманчылыгы, көнбатыштан – Аксубай урманчылыгы һәм Нурлат урманчылыгы белән чиктәш, көньяктан Самар өлкәсе белән чиктәш.

Территорияләрендә урман фонды урнашкан муниципаль районның урманлы өлеше 25 процент тәшкил итә.

Урманчылык территориясе бүлеп күрсәтелгән Татарстан Республикасы 1 нче схематик каратада күрсәтелгән.

1 нче карта-схема




Экспликация:

| № | Наименование лесничества | № | Наименование лесничества |
|---|---|---|---|
| 1 | Агрызское лесничество | 17 | Калейкинское лесничество |
| 2 | Азнакаевское лесничество | 18 | Камское лесничество |
| 3 | Аксубаевское лесничество | 19 | Кзыл-Юлдузское лесничество |
| 4 | Алькеевское лесничество | 20 | Лаишевское лесничество |
| 5 | Альметьевское лесничество | 21 | Лениногорское лесничество |
| 6 | Арское лесничество | 22 | Лубяжское лесничество |
| 7 | Бавлинское лесничество | 23 | Мамадышское лесничество |
| 8 | Билярское лесничество | 24 | Мензелинское лесничество |
| 9 | Болгарское лесничество | 25 | Нижнекамское лесничество |
| 10 | Бугульминское лесничество | 26 | Нурлатское лесничество |
| 11 | Буинское лесничество | 27 | Приволжское лесничество |
| 12 | Елабужское лесничество | 28 | Пригородное лесничество |
| 13 | Заинское лесничество | 29 | Сабинское лесничество |
| 14 | Зеленодольское лесничество | 30 | Тетюшское лесничество |
| 15 | Ислейтарское лесничество | 31 | Черемшанское лесничество |
| 16 | Кайбицкое лесничество | | |

### 1.1.3. Урманнарны урман үсү зоналарына, урманлы районнарга һәм урманнарны саклау һәм урман орлыкчылыгы районнарына бүлү

Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерыгы белән расланган урман үсү районнарына бүленеш нигезендә урманчылык территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала районына кертелгән (2 нче таблица).

2 нче таблица

Урманчылык урманнарын урман үсә торган зоналарга һәм урманлы районнарга бүлү

| Т/с | Кишәрлек урманчылыкларының аталышы | Урман үсә торган зона | Урманлы район | Саклык районнарына бүлү зонасы | Урман орлыкчылыгы районнарына бүлү | Урман кварталлары исемлеге | Мәйданы, гектар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Казанка | Урман-дала зонасы | Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала районы | Урман авырулары буенча уртача хәтәрлек | Нарат өчен - 3, чыршы - 4, имән - 2 | 1-81 | 10325 |
| 2. | Светлогорск | | | | | 1-92 | 13162 |
| 3. | Чишмә икенче | | | | | 1-138 | 13048 |
| барлыгы | | | | | | | 36535 |

Урманчылык территориясенең һәм кишәрлек урманчылыкларының урманнар үсә торган зоналарга һәм урманлы районнарга бүленеше 2 нче схематик картада күрсәтелгән.

2 нче карта-схема



## 1.1.4. Урманчылык урманнарының кварталлар яисә аларның өлешләре буенча максатчан билгеләнеше һәм саклагыч урман категорияләре буенча бүленеше, шулай ук саклагыч, эксплуатация һәм резерв урманнарын бүлеп чыгару нигезләре

3 нче таблица

Урманнарның максатчан билгеләнеше һәм саклык урман категорияләре буенча бүленеше

| Т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйданы, гектар | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Җәмгысе урманнар, шул исәптән | | | 36535 | |
| 2. | 1. Саклагыч урманнар барлыгы, шул исәптән | | | 3475 | |
| 3. | 1.1. су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Казанка | Квартал өлешләре: 27, 28, 71, 75, 80 | 36 | РФ Урман кодексы, РФ Су кодексы «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге 232 номерлы Рослесхоз боерыгы |
| | | Светлогорск | Квартал: 84, квартал өлешләре: 82, 85-90 | 102 | |
| | | Чишмә икенче | Кварталлар: 129-131, квартал өлешләре: 28, 29, 41, 53, 63, 64, 71, 72, 76, 80, 124, 126, 134, 136, 138 | 150 | |
| | | барлыгы | | 288 | |
| 4. | 1.2. табигый һәм башка объектларны саклау вазыйфасын үтәүче урманнар, шул исәптән, барлыгы: | | | 516 | |
| 5. | 1.2.1. саклагыч урман полосаларында урнашкан урманнар | Казанка | Квартал өлешләре: 1, 7, 10, 11, 12, 13, 15, 23, 31, 33, 35, 38, 39, 45, 46, 47, 55, 73, 76, 80 | 294 | РФ Урман кодексы, «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле урманнарга, эксплуатация урманнарына кертү |
| | | Светлогорск | Квартал өлешләре: 15, 39, 67, 74, 81 | 116 | |
Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю

| Т/с | Азык-төлек урман ресурсларының, дару үләннәренең төре | Үлчәү берәмлеге | Әзерләүгә ел саен рөхсәт ителә торган күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Азык-төлек ресурслары | | | |
| 1. | Җиләкләр: нарат җиләге | тонна | - |
| | Мүк җиләге | тонна | - |
| | Күк җиләк | тонна | - |
| | кура җиләге | тонна | - |
| | җир җиләге | тонна | - |
| | кара җиләк | тонна | - |
| | кызыл бөрлегән | тонна | - |
| | миләш, шомырт | тонна | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Җәмгысе: | тонна | - |
| 2. | Гөмбә: ак | тонна | - |
| | майлы | тонна | - |
| | ал гөмбә | тонна | - |
| | кызыл гөмбә | тонна | - |
| | каен гөмбәсе | тонна | - |
| | гөреждәләр | тонна | - |
| | әтәч гөмбәсе | тонна | - |
| | баллы гөмбә | тонна | - |
| | Барлыгы | тонна | - |
| 3. | Агач соклары: каен | тонна | - |
| Дару чималы | | | |
| 4. | Сары мәтрүшкә, икеөйле кычыткан, ландыш, аю табаны, дару ромашкасы, акбаш, эт тигәнәге, канлы үлән, песи үләне, сәдәп гөле, лапчатка, үги ана яфрагы, кыр наратбашы һ.б. | тонна | |
| 5. | Чага гөмбәсе | тонна | - |

Җиләк, гөмбә һәм дару чималлары уңышының 90 процентына кадәр өлеше җирле халык тарафыннан үзләштерелә.

### 2.4.2. Әзерләү һәм җыеп алу вакытлары

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәре җыю өчен урманнардан рөхсәтле файдалану чорлары урман кишәрлегенең аренда шартнамәсендә билгеләнә.

### 2.4.3. Агач сутлары әзерләгәндә нормативлар һәм параметрлар

Каен суты әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәренә 5 елдан да ким булмаган вакыт кала рөхсәт ителә.

Каен суты әзерләү сайланма кисүләр башкарыла торган утыртмаларда кирт салу ысулы белән гамәлгә ашырыла, кисүгә билгеләнгән агачлардан алу рөхсәт ителә.

Кисеп җибәрү өчен тулылыгы кимендә 0,4 һәм бер гектарга кимендә 200 данә агачлы, бонитетның I-III классларына караган урманның сәламәт өлеше сайлап алына. Кисеп җибәргәндә күкрәк биеклегендәге диаметры 20 см һәм аннан да юанрак булган агачларны билгелиләр.

Агач тамыры башланган җирдән 20-35 см биеклектә канал бораулау эшләрен башкаралар. Агачта бер һәм аннан да күбрәк кирт салу тишекләре ясалган очракта, алар кәүсәнең бер ягында бер-берсеннән, сут бер савытка агып төшәрлек итеп, 8-15 см ераклыкта урнаштырыла.

Агач диаметрына карап, бораулана торган каналлар саны нормативлары киләсе таблицада китерелгән.

<table>
<tr><th>Агачның күкрәк биеклегендәге диаметры, см</th><th>Кирт салганда каналлар саны</th><th>Искәрмә</th></tr>
<tr><td>20-22</td><td>1</td><td rowspan="4">Диаметры 16 см булган агачларга кисәргә бер ел калгач кирт салу рөхсәт ителә, түбәндәгечә басым нормалары булганда:<br>16-20 см – 1 канал<br>21-24 см – 2 канал<br>25 см һәм күбрәк – 3 канал</td></tr>
<tr><td>23-27</td><td>2</td></tr>
<tr><td>28-32</td><td>3</td></tr>
<tr><td>33 һәм аннан күбрәк</td><td>3</td></tr>
</table>

Кирт салу чоры тәмамланганнан соң, агачларның чирләп китүен кисәтү максатларында, тишекләр сагыз пастасы белән сылап куелырга яисә агач бөке белән ябылырга һәм вар, бакча замазкасы яисә известьлы балчык белән сылап куелырга тиеш.

Калган елларда каналлар беренче елгы кисеп җибәрү каналлары дәрәҗәсендә 10 см интервал белән агач кәүсәсе әйләнесенең теге яисә бу ягына таба бораулана.

Әзерләү агачның техник сыйфатларын саклап калырлык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.

### 2.4.4. Абага-кара абага әзерләү

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү аларның үсентеләренә зыян китермәслек алымнар белән гамәлгә ашырылырга тиеш. Үсемлекләрне тамыры белән йолкып алу, яфракларына һәм тамыр үзәгенә зыян китерү тыела.

Кара абага чималын әзерләү бер кишәрлектә 3-4 ел дәвамында алып барыла. Аннары үсемлекләрне торгызу өчен тәнәфес кирәк: чималны бер тапкыр җыйган вакытта (бер сезонда) – 2-3 ел, ике тапкыр җыйган очракта – 3-4 ел.

### 2.4.5. Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен файдалану чорлары

Дәүләти яисә муниципаль милектәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе, азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю өчен урманнардан файдалану максатларында, РФ Урман кодексының 72 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ун елдан алып кырык тугыз елга кадәр төзелә.

Урман кишәрлегенең аренда шартнамәсенең вакыты урман хуҗалыгы регламентында урманнардан файдалану буенча каралган чорга туры китереп билгеләнә.

## 2.5. Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Аучылык хуҗалыгы кыргый хайваннарның популяцияләре белән рациональ идарә итү һәм ел саен продукция алу рәвешендә урманнардан комплекслы файдалануга үз өлешен кертә.

Ау 209-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен файдалану РФ Урман кодексының 25, 36 статьялары белән регламентлана.

Урманнардан ау хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен аучылык хуҗалыгын алып бару өчен файдалануны хокукый җайга салу Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлекләрен бирмичә аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2017 елның 12 декабрендәге 661 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмә-тенең «Аучылык инфраструктурасына карый торган объектлар исемлеге турында» 2017 елның 11 июлендәге 1469-р номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Аучылык биләмәләре чикләренә хокукый режимында аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен башкару рөхсәт ителә торган җирләр кертелә.

Аучылык биләмәләре түбәндәгеләргә бүленә:

1) 209-ФЗ номерлы федераль законда каралган нигезләрдә юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан файдаланыла торган аучылык биләмәләре (алга таба – беркетелгән аучылык биләмәләре);

2) ау максатларында физик затлар ирекле йөри алу хокукына ия булган аучылык биләмәләре (алга таба – гомуми файдаланудагы аучылык биләмәләре).

Гомуми файдаланудагы аучылык биләмәләре Россия Федерациясе субъектындагы аучылык биләмәләренең гомуми мәйданында кимендә 20 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Аучылык биләмәләре ауның бер яки берничә төрен гамәлгә ашыру өчен кулланылырга мөмкин.

Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урман кварталларының һәм урманчылык кишәрлекләре буенча аларның өлешләре исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелгән.

### 2.5.1. Аучылык инфраструктурасы объектларын урнаштыру өчен рөхсәт ителгән биотехник чаралар уздыру исемлеге һәм нормалары

Ел саен уздырыла торган биотехник чаралар күләме түбәндәге таблицада чагылдырылган.

Ел саен уздырыла торган биотехник чаралар күләме

| Т/с | Чараларның төрләре | Үлчәү берәм-леге | Ел саен рөхсәт ителә торган |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Ашату мәйданнары кору | данә | 6 |
| 2. | Пошилар өчен җимлекләр урнаштыру | данә | 20 |
| 3. | Тозлыклар урнаштыру | данә/тонна | 20 |
| 4. | Усак, тал кисү | куб.м | 6 |
| 5. | Аучы манаралары урнаштыру | данә | - |
| 6. | Ашату өчен печән әзерләү | тонна | - |
| 7. | Чуер ташлыклар кору | данә | - |
| 8. | Гөрелдәвекләр кору | данә | - |
| 9. | Кабан өчен ашату кырлары ясау | гектар | - |
| 10. | Ауны чикли һәм тыя торган аншлаглар, күрсәткечләр урнаштыру | данә | 6 |

## 2.6. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә генә урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 2 июлендәге 408 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә генә урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләре белән регламентлана.

Урманнар авыл хуҗалыгы алып бару (печән чабу, авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү, умартачылык, төньяк боланчылыгы, товарлы аквакультура (товарлы балыкчылык), авыл хуҗалыгы культураларын үстерү һәм башка авыл хуҗалыгы эшчәнлеге) өчен кулланылырга мөмкин, урман кишәрлеген биреп яки бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә гамәлгә ашырыла.

Авыл хуҗалыгын алып бару өчен урман кварталларының һәм урманчылык кишәрлекләре буенча аларның өлешләре исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелгән.

### 2.6.1. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану параметрлары

14 нче таблица

Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану параметрлары

| Т/с | Файдалану төрләре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен рөхсәт ителә торган күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Сөрүлекләр | гектар | 46 |
| 2. | Печән чабу | гектар | 329/230 |
| 3. | Авыл хуҗалыгы терлекләре көтү | | |
| | а) урманда | мең гектар/баш | - |
| | б) утлавыкларда, җәйләүләрдә | гектар/баш | 59 |
| 4. | Умартачылык | | |
| | а) бал бирүчеләр | | |
| | - юкә | гектар | 8376 |
| | - үләннәр | гектар | 507 |
| | б) бал продуктлылыгы, шул исәптән: | | |
| | - юкә | кг/гектар | 100 |
| | - үләннәр | кг/гектар | 100 |
| | в) умарта оялары күләмен тәэмин итү мөмкинлеге | умарталык саны | 1850 |

### 2.7. Балыкчылыкны гамәлгә ашыру, һәвәскәрләрчә балык тотудан тыш

Балыкчылыкны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану РФ Урман кодексының 38.1 статьясы һәм Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнардан балыкчылыкны гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 13 октябрендәге 742 номерлы боерыгы белән регламентлана.

Урманнардан файдалануның бу төре алар урнашкан җирләрнең максатчан билгеләнеше белән бәйле һәм аны алып бару урман хуҗалыгы мәнфәгатьләре белән туры килсә генә рөхсәт ителә.

Балык тоту өчен кишәрлек урманчылыклары буенча урман кварталлары яки аларның өлешләре исемлеге, һәвәскәрләрчә балык тотудан тыш, әлеге Регламентның 5 нче таблицасында китерелгән.

### 2.8. Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген һәм мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

РФ Урман кодексының 40 статьясына ярашлы рәвештә урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану урманчылыкның барча территориясендә гамәлгә ашырылырга мөмкин. Урманнардан файдалану Россия Табигать ресурслары һәм экология

министрлыгының «Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 487 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләре белән регламентлана.

Фәнни-тикшеренү, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урман кварталларының һәм урманчылык кишәрлекләре буенча аларның өлешләре исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелде.

## 2.9. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

### 2.9.1. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары

Рекреация эшчәнлеге РФ Урман кодексында туризм, физик культура һәм спорт, ял оештыру һәм гражданнарның сәламәтлеген ныгыту өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү белән бәйле эшчәнлек буларак карала.

Урманнардан шушы рәвешле файдалану (РФ Урман кодексының 41 статьясында) урман кишәрлекләре бирүне таләп итә торган төрләргә карый, әмма урман ресурсларыннан башка гына гамәлгә ашырыла, бирелгән урман кишәрлекләрендә кирәкле урман инфраструктурасы, шул исәптән капиталь һәм капиталь булмаган төзелмәләр һәм корылмалар булдырыла, территория төзекләндерелә (РФ Урман кодексының 13, 41 статьялары).

Рекреация эшчәнлеген оештыру үзенчәлекләре Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 908 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрендә бәян ителгән.

### 2.9.2. Рекреация эшчәнлегенә бәйле зона кварталларының һәм (яки) аларның өлешләре исемлеге

Кишәрлек урманчылыклары буенча рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урман кварталларының яки аларның өлешләренең исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелгән.

### 2.9.3. Рекреация эшчәнлегенә караган зона территориясен функциональ зоналарга бүлү

Рекреацияләү зоналары вазифаи зоналарга түбәндәгечә бүлгәләнә:

1. Интенсив файдаланулы.

2. Уртача файдаланулы.
3. Оешкан рәвештә ял итүле.
4. Резерватлы.
5. Заказник.
6. Катгый режимлы.
7. Хуҗалыкка бәйле.

### 2.9.4. Урман кишәрлекләрендә вакытлыча төзелгән корылмалар исемлеге һәм аларны төзекләндерү нормативлары

Рекреация билгеләнешендәге урманнарда территорияне төзекләндерү нормалары (гомуми мәйданның 100 гектары буенча)

| Т/с | Төзекләндерү элементлары | Яшел зона | | Чикләрендәге (1 км маршрутка) актив ял итүгә бәйле |
|---|---|---|---|---|
| | | Актив ял | Һава сулап йөрү | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Гравийлы, йөри торган өлеше 4,5 м (км) киңлегендә булган машина белән килү юллары | 0,15 | 0,02 | - |
| 2. | Биләмәләр эчендәге гравийлы, өслеге 3 м (км) киңлегендә булган юллар | 1,8 | 0,5 | - |
| 3. | 15 машинага исәпләнгән, грунтлы, гравий белән вак таш кушылган автотукталышлар (данә) | 0,25 | 0,03 | - |
| 4. | Җәяүләп йөри торган сукмаклар (км) | - | 0,04 | - |

### 2.9.5. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану параметрлары һәм чорлары

Рекреация эшчәнлеге урманнарында хуҗалык эшчәнлеге халыкны ял иттерү өчен иң яхшы шартларны оештыруга, эстетик һәм санитар-гигиеник таләпләргә җавап бирә торган урман ландшафтларын саклауга һәм яхшыртуга, ландшафтларның типларын рациональ (оптималь) ярашлылыгын билгеләүгә юнәлдерелгән булырга тиеш.

Рекреация билгеләнешендәге урманнар өчен эшләрнең әһәмиятле элементы булып аларның территорияләрен төзекләндерү тора, ул юллар төзү һәм ремонтлаудан, ял итү өчен урыннар һәм мәйданчыклар корудан, кече архитектура формаларын, урман скульптурасын урнаштырудан, төрле урман янгыннары корылмаларын төзүдән һәм башка төрле чараларны гамәлгә ашырудан гыйбарәт. Юл-сукмак челтәре барча территорияне бердәм композиция бөтенлегенә берләштерергә тиеш.

Рекреация басымы йогынтысында урман тирәлегенең үзгәрү дәрәҗәсен ял итү режимы билгели, ә ял режимы - урманнарның территориясен оештыруны.

Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланганда урман кишәрлекләрендә капиталь һәм капиталь булмаган төзелмә объектлары, корылмалар исемлеге һәм аларны төзекләндерү нормативлары өстәмә тикшерүләр уздырганнан соң урманнарны үзләштерү проектларында аталган максатларда (ял, туризм оештыру, физик культура-савыктыру, спорт эшчәнлеге һ.б.) файдалану өчен тапшырылган конкрет урман кишәрлеге өчен бирелә.

РФ Урман кодексының 72 статьясы нигезендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатында урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе ун елдан алып кырык тугыз елга кадәрле срокка төзелә.

## 2.10. Урманнардан урман плантацияләре ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урман плантацияләрен оештыру һәм аларны эксплуатацияләү билгеле бер токым (максатчан токым) урман үсемлекләрен үстерүгә бәйле эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Билегеле бер токым урман утыртмаларына алар хисабыннан алдан билгеле сыйфатламалары булган агач материалын алу тәэмин итеlә торган ясалма утыртылган урман утыртмалары карый.

Урман плантацияләре урман фонды җирләрендә дә, башка категориядәге җирләрдә дә оештырыла ала.

Гражданнарга, юридик затларга урман плантацияләрен ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләре – РФ Урман кодексы нигезендә, җир кишәрлекләре – җир законнары нигезендә арендага тапшырыла.

Урман плантацияләрендә урман утыртмаларын кисү һәм урман утыртмаларына кирт салу эшләрен башкару чикләүләрсез рөхсәт ителә.

Урманчылыкта урман плантацияләре, урман плантацияләрен техник проектлау материаллары юк, урманчылыкта урман плантацияләренә нигез салу өчен махсус тикшерүләр уздырылмады.

РФ Урман кодексының 72 статьясы нигезендә урман плантацияләрен оештыру һәм аларны эксплуатацияләү максатында урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе ун елдан алып кырык тугыз елга кадәрле срокка төзелә.

## 2.11. Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен һәм дару үләннәрен үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урман җимешләрен, җиләкләрне, декоратив үсемлекләрне һәм дару үләннәрен үстерү җимешләр, декоратив үсемлекләр, дару үләннәре, җиләкләр һәм башка шуңа охшаш урман ресурсларын алуга бәйле эшмәкәрлек эшчәнлегеннән гыйбарәт. Урманнардан файдалануның әлеге төре Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 497 номерлы боерыгы белән расланган

Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрендә регламентлана һәм урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе нигезендә урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләр, шулай ук урман булып җитешмәгән, агачлар киселгән урыннар, аланнар һәм урман культураларын утыртканчыга кадәр урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман утыртмалары белән капланмаган җирләр; рекультивацияләнергә тиешле (эшкә яраклы үзлеге беткән торфлыклар һ.б.) җирләр файдаланыла.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен үзгәртеп коруга билгеләнмәгән, азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин.

Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану РФ Урман кодексының 27 статьясы нигезендә чикләнергә яки тыелырга мөмкин.

РФ Урман кодексының 72 статьясы нигезендә җмешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү максатында урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе ун елдан алып кырык тугыз елга кадәрле срокка төзелә.

Кишәрлек урманчылыклары буенча җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен урман кварталларының яки аларның өлешләренең исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелгән.

## 2.12. Урманнардан урман питомниклары ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урман питомникларын (даими, вакытлыча) булдыру һәм аларны эксплуатацияләү төп урман агач токымнары үсентеләрен үстерү белән бәйле эшчәнлек булып тора.

Урман питомникларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү кагыйдәләре Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман питомникларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 12 октябрендәге 737 номерлы боерыгы белән расланган.

Урман питомниклары булдыру һәм алардан файдалану өчен урманнардан файдалану РФ Урман кодексының 27 статьясы нигезендә чикләнергә мөмкин.

Урман питомниклары төзү һәм аларны файдалану, әгәр мондый эшчәнлек аларның хокукый режимына каршы килмәсә, урман фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрдә рөхсәт ителә (РФ Урман кодексының 39.1 статьясы).

Урман питомникларында кәлшәләр, үсентеләр үстерү өчен яхшыртылган һәм сортлы урман үсемлекләре кулланыла, әгәр мондый орлыклар юк икән, урман үсемлекләренең нормаль орлыклары кулланыла.

РФ Урман кодексының 72 статьясы нигезендә урман питомниклары оештыру һәм аларны эксплуатацияләү максатында урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе ун елдан алып кырык тугыз елга кадәрле чорга төзелә.

Урман питомниклары булдыру һәм аларны кишәрлек урманчылыклары буенча эксплуатацияләү өчен урман кварталлары яисә аларның өлешләре исемлеге әлеге Регламентның 5 нче таблицасында китерелә.

Хәзерге вакытта Чирмешән урманчылыгы чикләрендә бер даими урман питомнигы бар, аларда төп урман хасил итүче токымнар үстерелә.

## 2.13. Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, эзләү һәм файдалы казылмалар чыгаруны гамәлгә ашыру өчен файдалану РФ Урман кодексының 43 статьясы, Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, эзләү һәм файдалы казылмалар чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану тәртибен һәм, җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру максатларында, урман кишәрлеге бирелмичә, сервитут билгеләп яки билгеләмичә урманнардан файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 7 июлендәге 417 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалануның рөхсәт ителгән күләмнәре һәм урманчылыкларның кишәрлек урманчылыклары кисемендә урман кишәрлекләренең урнашкан урыны 5 нче таблицада чагылдырылган.

Урманнарны җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару максатларында файдалану өчен дәүләт яки муниципаль милектәге урман кишәрлеге арендага бирелә яки бу урман кишәрлегенә карата РФ Урман кодексының 9 статьясына ярашлы рәвештә сервитут билгеләнергә мөмкин. Урманнарны урман кишәрлеген бирмичә, сервитут билгеләмичә генә җир астын геологик өйрәнү максатларында файдалану рөхсәт ителә, әгәр күрсәтелгән максатларда эш башкару урман утыртмаларын кисүгә яки капиталь төзелеш объектларын төзүгә китермәсә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару максатында урманнардан файдалана торган затлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

кулланыла торган урманнарны һәм урманга тоташкан урман кашакларны, ясалма һәм табигый су агымнарын җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычранудан даими чистарту;

җитештерү эшчәнлеге барышында җимерелгән юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, күперләрне, башка гидротехник корылмаларны, квартал баганаларын, квартал юлларын, аншлагларны, урманнар территориясен төзекләндерү элементларын торгызуны;

Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган, җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыруга бәйле объектларны тиешле

эшләрне үтәү чорлары тәмамлану белән консервацияләүне яисә юк итүне һәм күрсәтелгән объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм (яки) эксплуатацияләү өчен файдаланылган җирләрне рекультивацияләүне;

әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, шулай ук аларның нәтиҗәләрен бетерү буенча кирәкле чараларны күрү;

сейсмик разведка эшләрен планлаштыру һәм үткәрү, шулай ук хәрәкәт составын һәм йөкләрне яңа урынга күчерү максатларында квартал ызаннары, урман юллары биләгән һәм урман утыртмалары белән капланмаган башка җирләрдән актив файдалану.

РФ Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урманнардан файдаланганда алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була.

Әлеге агач материалы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан файдаланганда алынган агач материалын сату турында» 2009 елның 23 июлендәге 604 номерлы карары нигезендә сатыла.

РФ Урман кодексының 73.1 статьясының 3 өлешендә РФ Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урманнардан файдалану өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә агач материалы әзерләү өчен аукцион уздырмыйча урман кишәрлекләренең аренда шартнамәләрен төзү каралган.

РФ Урман кодексының 73.1 статьясының 3 өлешендәге 3 пунктында 43, 45 статьяларда каралган очракларда, дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган урман кишәрлеген файдалануга алу шартнамәсе җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия гамәлдә булган чорга төзелә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру максатлары өчен урман кварталлары яисә аларның өлешләре исемлеге әлеге Регламентның 5 нче таблицасында китерелә.

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм урманнарны торгызуны һәм урман үрчетүне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 212-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 303-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә әлеге максатларда урманнардан файдаланучы затлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә урманнарны торгызу проектына яки урманнарны үрчетү проектына ярашлы рәвештә урман утыртмаларын кисәннән соң бер елдан соңга калмыйча урман утыртмалары киселгән мәйданга тигез мәйданда Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урманнарны торгызу яки урманнарны үрчетү эшләрен башкарырга бурычлы, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны оештыру өчен билгеләнгән саклык зоналарын булдырган очракта да.

## 2.14. Урманнардан сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портлары булдыру һәм аларны киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

РФ Урман кодексының 44 статьясына ярашлы рәвештә, урман кишәрлекләре сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портларын булдыру һәм аларны киңәйтү, су законнарына ярашлы рәвештә гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла.

Урман законнары нормаларында билгеләнгәнчә, РФ Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урманнардан файдаланганда алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була.

Әлеге агач материалы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан файдаланганда алынган агач материалын сату турында» 2009 елның 23 июлендәге 604 номерлы карары нигезендә сатыла.

РФ Урман кодексының 72 статьясының 3 өлеше һәм 74 статьясының 3 өлеше нигезендә урман кишәрлекләре атап үтелгән максатларда дәүләт органнары карарлары нигезендә, аукционнар уздырмыйча гына, бер елдан алып кырык тугыз елга кадәрге чорга арендага тапшырыла.

Дәүләт яки муниципаль милектәге урман кишәрлекләре гражданнарга, юридик затларга РФ Урман кодексының 9 статьясына ярашлы рәвештә сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портларын булдыру һәм аларны киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә.

Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портларын булдыру һәм аларны киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү өчен кишәрлек урманчылыклары буенча урман кварталлары яки аларның өлешләре исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелгән.

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерүне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 212-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 303-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә әлеге максатларда урманнардан файдаланучы затлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә урманнарны торгызу проектына яки урманнарны үстерү проектына ярашлы рәвештә урман утыртмаларын кискәннән соң бер елдан соңга калмыйча урман утыртмалары киселгән мәйданга тигез мәйданда Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урманнарны торгызу яки урманнарны үрчетү эшләрен башкарырга бурычлы, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм объектларны

эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны оештыру өчен билгеләнгән саклык зоналарын булдырган очракта да.

## 2.15. Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 1 статьясының 10.1 пунктына ярашлы рәвештә, линияле объектларга электр тапшыру линияләре, элемтә линияләре (шул исәптән линия-кабель корылмалары), торбаүткәргечләр, автомобиль юллары, тимер юл линияләре һәм башка шундый корылмалар керә.

Урманнардан файдалануның әлеге төре РФ Урман кодексының 45 статьясы һәм Россия Табигать министрлыгының «Урманнардан линияле объектлар төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану кагыйдәләрен һәм, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә, урман кишәрлеген бирмичә урманнардан линияле объектлар төзү, аларны үзгәртеп кору, аларны эшләтү өчен файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 10 июлендәге 434 номерлы боерыгы нигезендә регламентлана.

Сусаклагычлар, бүтән ясалма су объектлары, шулай ук гидротехник корылмалар, елга портлары, причаллар төзү өчен гражданнарга һәм юридик затларга урманчылыкның барча территориясе буйлап урман кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшыру аренда хокукында гамәлгә ашырылырга мөмкин, ә махсус саклanучы урман кишәрлекләрендә фәкать күрсәтелгән эшләрне урнаштыру ихтималының башка вариантлары булмаган очракта гына рөхсәт ителә.

Дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган урман кишәрлекләре гражданнарга һәм юридик затларга РФ Урман кодексының 9 статьясы һәм 73.1 статьясының 3 өлеше нигезендә аукцион уздырмыйча кырык тугыз елга кадәр бирелә.

Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарны төзелеш, реконструкция, линияле объектларны эксплуатацияләү белән бәйле объектларны урнаштыру өчен кулланганда урман булмаган җирләр, ә андый җирләр булмаганда – урманны торгызу өчен билгеләнгән җирләр (киселгән, янган, сирәкләнгән, чүлгә әверелгән урыннар, аланлыклар һәм башка урыннар), шулай ук түбән тулылыклы һәм аз дәрәҗәдә кыйммәтле урман агачлары үскән мәйданнар кулланылырга тиеш.

Линияле объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү максатларында арендага, даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшырылган урман кишәрлекләрендә урман утыртмаларын кисү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш. Урманнардан файдалануның әлеге төрендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан шушы рәвешле файдаланганда алынган агач материалына милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була (РФ Урман кодексының 20 статьясының 2 өлеше). Әлеге агач материалын сату РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Урман кодексының 43-46 статьялары нигезендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан файдаланганда алынган агач материалын сату турында» 2009 елның 23 июлендәге 604 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм линияле объектларны

эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны тудыру өчен билгеләнгән сак һәм санитар-саклык зоналарында урман утыртмаларын кисү күрсәтелгән зоналарда билгеләнгән режимга туры китереп гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының саклык зоналарын һәм мондый зоналарның чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануда махсус шартлар билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары нигезендә көчәнеше 1000 вольтка кадәр булган электр челтәрләре өчен түбәндәгечә саклык зонасы билгеләнә:

электр тапшыру һава линияләре буйлап (биналарга кертү өлешендәге тармакларыннан тыш) җир өслегендә кырый үткәргечләр проекцияләреннән һәр ягыннан 2 метр ераклыкта торучы, параллель турылар белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә (алар үз торышыннан читкә чыгып тормаганда);

җир астыннан электр тапшыручы кабель линияләре буйлап кырый кабельләрдән һәр ягыннан 1 метр ераклыкта торучы, паралелль турылар белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә.

1000 В югары булган электр челтәрләренең саклык зонасы киләсе таблицага туры китереп билгеләнә.

Көчәнеше 1000 В югары булган электр челтәрләренең саклык зонасы

| т/с | Көчәнешнең проектта каралган номинал классы, кВт | Саклык зонасы, м |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | 1 кадәр | 2 (биналарның стеналары, конструкцияләр һ.б. буйлап үзтотышлы яки изоляцияләнгән үткәргечле линияләр өчен саклык зонасы мондый линияләрдән норматив хокукый актларда билгеләнгән минималь мөмкин аралык белән билгеләнә) |
| 2. | 1-20 | 10 (5 – торак пунктлар чикләрендә урнаштырылган үзтотышлы яки изоляцияләнгән чыбыклы линияләр өчен) |
| 3. | 35 | 15 |
| 4. | 110 | 20 |
| 5. | 150, 220 | 25 |
| 6. | 330, 500, +/- 400 | 30 |
| 7. | 750, +/- 750 | 40 |
| 8. | 1150 | 55 |

Торбаүткәргечләргә (алар нинди ысул белән салынган булса да) зыян салыну ихтималын булдырмас өчен саклык зоналары билгеләнә:

нефть, табигый газ, нефть продуктлары, нефть һәм ясалма углеводород газы транспортлаучы торбаүткәргеч трассалары буйлап, – торбаүткәргеч күчәренең һәр ягыннан 25 м ераклыкта узучы шартлы сызыклар белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә;

сыегайтылган углеводородлы газлар, тотрыклы булмаган бензин һәм конденсат транспортлаучы торбаүткәргеч трассалары буйлап, – торбаүткәргеч күчәренең һәр ягыннан 100 м ераклыкта уза торган шартлы сызыклар белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә;

күптармаклы торбаүткәргеч трассалары буйлап  кырый торбаүткәргечләрнең күчәрләреннән югарыда күрсәтелгән аралыкларда уза торган шартлы сызыклар белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә;

су асты кичүләре буйлап – кичүләрнең кырый тармаклары күчәрләреннән һәр ягыннан 100 м аралыкта торучы параллель яссылыклардан гыйбарәт булган су өслегеннән төпкә кадәрге су тирәлегенең бер өлеше рәвешендә;

конденсатны саклау һәм газсызландыру савытлары, продукцияне аварияле чыгару өчен җир амбарлары тирәли – күрсәтелгән объектлар территориясе чикләренең һәр ягыннан 50 м ераклыкта торучы, йомык сызык белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә;

продукцияне транспортка әзерләүче технологик җайланмалар, суырту һәм тутыру буенча төп һәм аралык насос станцияләре, резервуар парклары, компрессор һәм газ бүлү станцияләре, продукцияне үлчәү төеннәре, салу һәм бушату эстакадалары, газны җир астында саклау станцияләре, нефть, нефть продуктларын җылыту пунктлары тирәли – күрсәтелгән объектларның территорияләре чикләреннән һәр ягыннан 100 м торучы йомык сызыклар белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә (Магистраль торбаүткәргечләрне саклау кагыйдәләре (Россиянең Федераль тау һәм сәнәгый күзәтчелегенең 1992 елның 24 апрелендәге 9 номерлы карары белән расланган) (Россиянең Федераль тау һәм сәнәгый күзәтчелегенең 1994 елның 23 ноябрендәге 61 номерлы карары редакциясендә).

Аерып чыгару полосаларының чикләре аерып чыгару полосасын формалаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләрен аерып чыгаруның Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы раслаган нормаларын исәпкә алып билгеләнә.

Аерып чыгару полосаларының һәм саклык зоналарының зурлыклары РФ Транспорт министрлыгының «Тимер юлларны аерып чыгару полосаларын формалаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләрен аерып чыгару нормаларын, шулай ук тимер юлларның саклык зоналарын исәпләп чыгару нормаларын раслау турында» 2008 елның 6 августындагы 126 номерлы боерыгында билгеләнгән Тимер юлларны аерып чыгару полосасын формалаштыру өчен кирәкле җир кишәрлекләрен аерып чыгару нормалары, шулай ук тимер юлларның саклык зоналарын исәпләп чыгару нормалары, җир корылышы, шәһәр төзелеше һәм проект документациясе, тимер юл линияләрен, төеннәрен һәм станцияләрен үстерүнең генераль схемалары нигезендә, шулай ук барлыкка килгән җирдән файдалану тәртибен һәм аерып чыгару полосаларының һәм саклык зоналарының элегрәк расланган зурлыкларын һәм чикләрен исәпкә алып билгеләнә.

Линияле объектларны төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен урман кварталларының яки аларның өлешләренең исемлеге кишәрлек урманчылыклары буенча әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелде.

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерүне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 212-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 303-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә әлеге максатларда урманнардан файдаланучы затлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә урманнарны торгызу

проектына яки урман үстерү проектына ярашлы рәвештә урман утыртмаларын кисkәннән соң бер елдан соңга калмыйча урман утыртмалары киселгән мәйданга тигез мәйданда Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урманнарны торгызу яки урманнарны үстерү эшләрен башкарырга бурычлы, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны оештыру өчен билгеләнгән саклык зоналарын булдырган очракта да.

## 2.16. Урманнардан урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнардан агач эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен файдалану агач һәм башка урман ресурсларын эшкәртү объектларын булдыру, алардан продукция җитештерүгә бәйле эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләрен куллану РФ Урман кодексының 46 статьясы, Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 54 номерлы боерыгы белән регламентлана.

Дәүләт яки муниципаль милектәге урман кишәрлекләре гражданнарга, юридик затларга урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен арендага бирелә.

Урманнардан агач материалы һәм башка төрле урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану максатында урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе бер елдан башлап кырык тугыз елга кадәрле чорга төзелә.

Әгәр федераль законнарда федераль дәүләт учреждениеләре тарафыннан урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителә икән, дәүләт милкендәге урман кишәрлекләре әлеге учреждениеләргә күрсәтелгән максатлар өчен даими (вакытын чикләмичә) файдалануга бирелә ала.

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын урнаштыру максатларында, барыннан да элек, урмансыз җирләр, ә урман кишәрлегендә андый җирләр булмаганда – кисүләрдән соң торгызылмаган кишәрлекләр, янган, сирәкләнгән җирләр, чүллекләр, ачык урыннар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман утыртмалары үсә торган җирләр файдаланыла.

Бүтән урман кишәрлекләреннән күрсәтелгән максатларда файдалану күрсәтелгән объектларны урнаштыруның башка вариантлары булмаганда рөхсәт ителә.

Саклагыч урманнарда булдыру, шулай ук Россия Федерациясе Урман кодексында һәм башка федераль законнарда каралган башка очракларда урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру һәм эксплуатацияләү тыела.

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда түбәндәге очраклар булмаска тиеш:

урманнарны пычрату (шул исәптән радиоактив һәм нефть матдәләре белән) һәм урманнарга башка төрле тискәре йогынты ясау;

Гражданнарның урманнарда булуына чикләүләр кертелгән очракта, транспорт чаралары белән урман кишәрлекләренә керү.

Кишәрлек урманчылыклары буенча урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен урман кварталлары яки аларның өлешләре исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелгән.

«Россия Федерациясе Урман кодексына һәм урманнарны яңадан үрчетү һәм урман үстерүне камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 212-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе Урман кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 303-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә әлеге максатларда урманнардан файдаланучы затлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә урманнарны торгызу проектына яки урман үстерү проектына ярашлы рәвештә урман утыртмаларын кискәннән соң бер елдан соңга калмыйча урман утыртмалары киселгән мәйданга тигез мәйданда Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урманнарны торгызу яки урманнарны үстерү эшләрен башкарырга бурычлы, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартларны оештыру өчен билгеләнгән саклык зоналарын булдырган очракта да.

## 2.17. Урманнардан дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнарны дини оешмалар 125-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен куллана ала.

Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә дини һәм хәйриячелек билгеләнешендәге биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне торгызу рөхсәт ителә. Дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган урман кишәрлекләре дини оешмаларга дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен түләүсез нигездә файдалануга тапшырыла (РФ Урман кодексының 47 статьясы).

Кишәрлек урманчылыклары буенча дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен урман кварталларының яки аларның өлешләренең исемлеге әлеге регламентның 5 нче таблицасында китерелгән.

## 2.18. Урманнарны саклауга һәм яңадан үрчетүгә карата таләпләр

### 2.18.1. Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларына, урманнарны радиоактив матдәләр белән пычранудан һәм тискәре башка йогынтыдан саклауга карата таләпләр

РФ Конституциясенең 9 статьясы һәм РФ Урман кодексының 51 статьясы нигезендә урманнар янгыннардан сакланырга тиеш.

Урманнарны янгыннардан саклау РФ Урман кодексы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» федераль закон нигезендә биологик, урманчылык, экологик һәм төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла һәм урманнардагы янгыннарны булдырмый калуга, вакытында ачыклауга һәм сүндерүгә юнәлдерелгән оештыру, хокукый һәм башка чаралар комплексын үз эченә ала.

Урманнардан файдаланганда, аларны саклаганда, яңадан үрчеткәндә, урманнарда башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашырганда, шулай ук урманнарда гражданнар йөргәндә урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча бердәм таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 7 октябрендәге 1614 номерлы карары белән расланган Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрендә билгеләнгән. Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары төрләре, урманнардан файдаланучы затларның әлеге чаралар белән тәэмин ителү нормативлары, урманнардан файдаланганда урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларын булдыру нормалары Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары төрләрен, урманнардан файдаланучы затларның әлеге чаралар белән тәэмин ителү нормативларын, урманнардан файдаланучы затларның урманнарны кулланганда урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларын булдыру нормаларын раслау турында» 2014 елның 28 мартындагы 161 номерлы боерыгы белән расланган. Урманнарның табигый янгын куркынычын классификацияләү, һава шартларына бәйле рәвештә урманнарда янгын куркынычын классификацияләү Рослесхозның «Урманнарның табигый янгын куркынычын классификацияләүне һәм һава шартларына бәйле рәвештә урманнарда янгын куркынычын классификацияләүне раслау турында» 2011 елның 05 июлендәге 287 номерлы боерыгы белән расланган.

Урманнарны янгыннардан саклауның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Рослесхозның «Янгын-химия станцияләре турында нигезләмә раслау турында» 1997 елның 19 декабрендәге 167 номерлы боерыгы белән Янгын-химия станцияләре турында нигезләмә расланган.

Чирмешән урманчылыгы мәйданының янгын куркынычы классларына бүленеше түбәндәге таблицада күрсәтелде.

Җирләрнең гомуми мәйданын табигый янгын куркынычы класслары буенча бүлү

мәйданы, га

| т/с | Атамасы | Янгын чыгу куркынычы классы | | | | | Барлы-гы | Уртача классы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | I. | II. | III. | IV. | V | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. | Чирмешән | 2426 | 1710 | 1990 | 28510 | 1899 | 36535 | 3.7 |
| % | | 6,6 | 4,6 | 5,45 | 78,03 | 5,2 | 100 | % |

Төп урман агач токымнарының яшәү өчен яраклы үсентеләре һәм яшь агачлары исәбенә бәйле рәвештә Кагыйдәләргә карата 1-41 кушымталарга кертелмәгән урман токымнары һәм урман үсү шартлары буенча урманнарны торгызу ысуллары урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентлары белән билгеләнә.

| Урман торгызу ысуллары | Агач токымнар | Урман типлары төркеме, урман үсү шартлары типлары | Яшәргә сәләтле шытым һәм үсенте саны, 1 гектарга мең данә |
|---|---|---|---|

| 1 | | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|---|
| Табигый урман торгызу | Шытымны саклау, үсентене карау юлы белән | Чыршы, карагай, яфраклы каты һәм йомшак токымнар | Коры | 4 артык |
| | | | Саф | 3 артык |
| | | | Дымлы | 2 артык |
| Табигый урман торгызу | Туфракны минераллаштыру юлы белән | Чыршы, карагай һәм яфраклы каты токымнар | Коры | 1-3 |
| | | | Саф | 0,5-1,5 |
| | | | Дымлы | 0,5-1 |
| Катнаш урман торгызу | | Яфраклы йомшак токымнар | Коры | 2-4 |
| | | | Саф | 1-3 |
| | | | Дымлы | 1-2 |
| Ясалма урман торгызу | | Чыршы, карагай һәм яфраклы каты токымнар | Коры | 1 ким |
| | | | Саф | 0,5 ким |
| | | | Дымлы | 0,5 ким |
| | | Яфраклы йомшак токымнар | Коры | 2 ким |
| | | | Саф | 1 ким |
| | | | Дымлы | 1 ким |

## 2.19. Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар буенча урманнардан файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре

РФ Табигать ресурслары министрлыгының «Россия Федерациясендә урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнар исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы 367 номерлы боерыгы нигезендә урманчылыкның барча территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала районында урнашкан.

Урман хуҗалыгы регламентында китерелгән нормативлар Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала зонасының урман-дала районына туры килә.

## 3 БҮЛЕК. Урманнардан файдалануда чикләүләр

### 3.1. Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләүләр

Урманнарны максатчан билгеләнеш төрләре һәм саклагыч урман категорияләре буенча чикләүләр 18 нче таблицада китерелде.

18 нче таблица

Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләүләр

| Т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Саклагыч урманнар | Саклагыч урманнарда тоташ кисүләрне уздыру РФ Урман кодексның 21 статьясының 6 өлешендә, 21.1 статьясының 2 өлешендә каралган очракларда һәм сайланма кисүләр үзләренең тирәлек хасил итә, су саклый торган, санитар-гигиеник, савыктыру һәм башка төрле функцияләрен югалта башлаган урман утыртмаларын саклагыч урманнарның максатчан билгеләнешен һәм алар башкара торган файдалы вазыйфаларны саклауны тәэмин итә торган урман утыртмаларына алмаштыруны тәэмин итмәгән очракларда гамәлгә ашырыла, әгәр Урман кодексында башкача билгеләнмәсә.<br>Саклагыч урманнарда аларның максатчан билгеләнеше һәм файдалы функцияләре белән туры килмәгән эшчәнлек алып бару тыела.<br>Саклагыч урманнарда урман эшкәртү инфраструктурасын төзү һәм эксплуатацияләү тыела |
| 2. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Тыела:<br>1) агулы химик препаратлар куллану;<br>2) авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу, умартачылык һәм товар аквакультурасы (товар өчен балыкчылык) чикләү булып тора;<br>3) урман плантацияләре төзү һәм алардан файдалану;<br>4) линияле объектлардан, гидротехник корылмалардан һәм нефть һәм табигый газ табу, эзләү һәм чыгару өчен кирәкле объектлардан, велосипед һәм йөгерү юлларыннан тыш, капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану.<br>5) урман эшкәртү инфраструктурасы ясау;<br>6) урман түшәмәсен җыю |
| 3. | Табигый һәм башка төр объектларны саклау вазыйфасын үтәүче урманнар | |
| 3.1 | а) урманнарның саклагыч полосаларында урнашкан урманнар | РФ Урман кодексының 21 статьясының 6 өлешендә, 21.1 статьясының 2 өлешендә каралган очраклардан тыш, урман утыртмаларын тоташ кисү тыела.<br>Тыела:<br>1) урман плантацияләре төзү; |

| Т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | 2) урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру;<br>3) урман түшәмәсен җыю |
| 3.2 | б) урман паркы зоналарында урнашкан урманнар | Тыела:<br>1) агулы химик препаратлар куллану;<br>2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару;<br>5) капиталь төзелеш объектларын төзү, велосипед һәм йөгерү юллары һәм гидротехник корылмалардан тыш.<br>Урманнар урнашкан җирләрнең чикләрен мондый җирләрнең мәйданын киметүгә китерергә мөмкин итеп үзгәртү рөхсәт ителми. |
| 3.3 | в) яшел зоналарда урнашкан урманнар | Тыела:<br>1) агулы химик препаратлар куллану;<br>2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру, әгәр күрсәтелгән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру урман утыртмаларын кисүне үткәрүгә яисә аучылык инфраструктурасы объектларын булдыруга китермәсә;<br>3) файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару;<br>4) авыл хуҗалыгын алып бару, печән чабу һәм умартачылыктан гайре, шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында коймалар кую;<br>5) капиталь төзелеш объектлары төзү һәм алардан файдалану, гидротехника корылмаларыннан, элемтә чыбыкларыннан, электр үткәрү чыбыкларыннан, җир асты торбаүткәргечләреннән гайре<br>Урманнар урнашкан җирләрнең чикләрен мондый җирләрнең мәйданын киметүгә китерергә мөмкин итеп үзгәртү рөхсәт ителми. |
| 4. | Кыйммәтле урманнар | Тыела:<br>1) капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, велосипед һәм йөгерү юллары, линияле объектлар һәм гидротехник корылмалардан тыш.<br>2) урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру;<br>3) урман плантацияләре булдыру максатында урманнардан файдалану<br>4) урман түшәмәсен җыю |
| 4.1 | Су объектлары буйларында урнашкан тыюлыклы урман полосалары | Линияле объектлардан, гидротехник корылмалардан һәм нефть һәм табигый газ табу, эзләү һәм чыгару өчен кирәкле объектлардан кала, капиталь төзелеш объектларын төзү һәм алардан файдалану. |
| 4.2 | Уылдык чәчү урыннарын саклаучы урман полосалары | РФ Урман кодексының 21 статьясының 6 өлешендә, 21.1 статьясының 2 өлешендә каралган очраклардан тыш, урман утыртмаларын тоташ кисү тыела.<br>Сайланма кисүләр үзләренең әйләнә-тирәлек хасил итү, су саклау, санитария-гигиена, савыктыру һәм башка төрле файдалы вазыйфаларын югалта баручы, саклагыч |

| Т/с | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | урманнарның максатчан билгеләнешен һәм алар үти торган файдалы вазыйфаларның сакланышын тәэмин итүче урман утыртмаларын алмаштырырга ирек бирмәгән очракта гына саклагыч урманнарда тоташ кисүләр гамәлгә ашырыла.<br>Бу категориядәге урманнарда бик зәгыйфь, зәгыйфь һәм уртача югары интенсивлыктагы урман утыртмаларына карата сайланма кисүләр алып барыла, интенсивлыгы һәлак булган, зыян күргән һәм кыйммәтсез агачларны кисү өчен Агач материалы әзерләү кагыйдәләрендә билгеләнгән бик югары интенсивлыкка ирешә ала торган санитар кисүләрдән тыш.<br>Тыела:<br>1) капиталь төзелеш объектлары урнаштыру, линияле объектлардан, гидротехник корылмалардан тыш;<br>2) урман эшкәртү инфраструктурасы ясау; |
| 5. | Эксплуатация урманнары | Урман кодексының 25 статьясында каралмаган максатларда урманнарны файдалану тыела. |

## 3.2. Махсус саклана торган урман кишәрлекләренең төрләре буенча чикләүләр

Урманнарның махсус сакланыла торган кишәрлекләрендә хокукый режим РФ Урман кодексының 119 статьясы, Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яңадан үрчетү үзенчәлекләрен раслау турында» 2021 елның 12 августындагы 558 номерлы боерыгы (алга таба – Үзенчәлекләр) белән регламентлана.

Махсус саклана торган урман кишәрлекләрендә аларның максатчан билгеләнеше белән файдалы үзлекләренә ярашмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыру тыела.

Махсус саклана торган урман кишәрлекләре төрләре буенча чикләүләр 19 нчы таблицада күрсәтелде.

19 нчы таблица

Махсус саклана торган урман кишәрлеге төрләре буенча чикләүләр

| Т/с | Махсус саклана торган урман кишәрлекләре төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су объектлары, чокыр сөзәклекләрендә урнашкан ярсаклагыч, туфраксаклагыч урман кишәрлекләре | Махсус саклана торган урман кишәрлекләрендә, РФ Урман кодексының 119 статьясының 3 өлешендә күрсәтелгәннәрдән тыш, түбәндәгеләр тыела:<br>1) РФ Урман кодексының 21 статьясының 6 өлешендә каралган очраклардан һәм сайланма кисүләр үз тирәлеген формалаштыручы, су саклау, санитар-гигиена, савыктыру |

| Т/с | Махсус саклана торган урман кишәрлекләре төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | һәм башка файдалы функцияләрен югалткан урман утыртмаларын саклык урманнарының максатчан билгеләнешен саклауны тәэмин итүче һәм үзләренең файдалы функцияләрен үти ала торган урман утыртмаларына алыштыруны тәэмин итмәгән очраклардан тыш, урман утыртмаларын тоташ кисү;<br>2) авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу, умартачылык һәм товар аквакультурасы (товар өчен балыкчылык) чикләү булып тора;<br>3) капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, линияле объектлар һәм гидротехник корылмалардан тыш;<br>Махсус саклана торган урман кишәрлекләрендә сайланма кисүләр уздыру фәкать һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү максатларында гына уздырыла.<br>РФ Су кодексына ярашлы рәвештә су саклау зоналары чикләрендә тыела:<br>1) туфракка ашлама кертү өчен агынты суларны файдалану;<br>2) зиратлар, үләт базлары, җитештерү һәм куллану калдыклары, радиоактив, химик, шартлаткыч, агулы, агулый торган һәм агулы матдәләр күмелгән урыннарны урнаштыру;<br>3) үсемлекләрнең корткычлары һәм авыруларына каршы көрәшү буенча авиация чараларын гамәлгә ашыру;<br>4) транспорт чаралары белән хәрәкәт итү һәм аларны туктатып калдыру (махсус транспорт чараларыннан тыш), аларның каты япмалы махсус җиһазландырылган юллардан һәм урыннарда хәрәкәт итүе һәм тукталып торуы искәрмә булып тора.<br>Яр буе саклык полосалары чикләрендә су саклау зоналары өчен билгеләнгән чикләүләр белән берлектә түбәндәгеләр тыела:<br>1) җирне эшкәртү;<br>2) юыла торган грунт өемнәрен урнаштыру;<br>3) авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү һәм алар өчен җәйге лагерьлар, ванналар оештыру. |
| 2. | Урмансыз киңлекләр белән чиктәш булып торучы урман кырыйлары | Махсус саклана торган урман кишәрлекләрендә, РФ Урман кодексының 119 статьясының 3 өлешендә күрсәтелгән-нәрдән тыш, түбәндәгеләр тыела:<br>1) РФ Урман кодексының 21 статьясының 6 өлешендә каралган очраклардан һәм сайланма кисүләр үз тирәлеген формалаштыручы, су саклау, санитар-гигиена, савыктыру һәм башка файдалы функцияләрен югалткан урман утыртмаларын саклык урманнарының максатчан билгеләнешен саклауны тәэмин итүче һәм үзләренең файдалы функцияләрен үти ала торган урман утыртмаларына алыштыруны тәэмин итмәгән очраклардан тыш, урман утыртмаларын тоташ кисү;<br>2) авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу, умартачылык һәм |
| 3. | Урман-орлык плантацияләре, даими урман-орлык кишәрлекләре һәм урман орлыкчылыгының башка объектлары | |
| 4. | Реликт һәм эндемик үсемлекләре булган урман кишәрлекләре | |
| 5. | Сирәк һәм югалу куркынычы янаган кыргый җәнлекләрнең | |

| Т/с | Махсус саклана торган урман кишәрлекләре төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | яшәү урыннары | товар аквакультурасы (товар өчен балыкчылык) чикләү булып тора;<br>3) капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, линияле объектлар һәм гидротехник корылмалардан тыш.<br>Махсус саклана торган урман кишәрлекләрендә сайланма кисүләр уздыру фәкать һәлак булган һәм зыян күргән урман утыртмаларын кисү максатларында гына уздырыла. |
| 6. | Табигый мирас объектлары | |
| 7. | Махсус саклланучы башка урман кишәрлекләре | |
| 8. | Тыюлы урман кишәрлекләре | Тыюлы урман кишәрлекләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>1) урман утыртмаларын кисү;<br>2) агулы химик препаратлар куллану;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару;<br>5) капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү |

Искәрмә: Махсус саклланучы урман кишәрлекләре урнашкан җир һәм аларның мәйданы урманнар коруны проектлаганда күрсәтелә.

### 3.3. Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр

Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләүләр түбәндәге таблицада китерелгән.

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Агач материалы әзерләү | Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләменнән (рөхсәт ителгән агач алу күләменнән) артып китүче күләмдә, шулай ук кисентеләрнең яшен бозып агач материалы әзерләү рөхсәт ителми (РФ Урман кодексының 29 статьясының 5 өлеше). Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда агач материалы әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 1 декабрендәге 993 номерлы боерыгы белән расланган РФ Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда агач материалы әзерләү кагыйдәләренең 12 пункты нигезендә:<br>а) елга һәм чишмә үзәннәрен сөйрәмә җир трассалары һәм урман юллары сыйфатында куллану рөхсәт ителми;<br>б) диләнкедән читтә, алар белән чиктәш булган 50 метрлы полосаларда урман утыртмаларын, үсемчелек катламын һәм туфракларны зарарлау, урманнарны сәнәгать һәм башка төрле калдыклар белән чүпләү рөхсәт ителми;<br>в) юлларга, күперләргә, урман ызаннарына, киптерү челтәренә, юл, гидромелиоратив һәм башка төрле корылмаларга, елга һәм чишмә үзәннәренә зыян салу рөхсәт ителми;<br>г) аударылыган һәм асылынып төшкән, киселгән агачларны |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | (киселгән һәм диләнкедә калдырылган агачларны исәпкә алып) калдыру, сакланырга тиешле яшь шытымны зарарлау яисә һәлак итү тыела;<br>д) чиктәш булып торучы, кварталлардагы, диләнкеләрдәге һәм башка баганаларны һәм тамгаларны юк итү тыела;<br>е) кисүгә тиешле булмаган һәм Россия Федерациясенең Агач материалы әзерләү кагыйдәләре һәм урман законнары нигезендә сакланырга тиешле агачларны, шул исәптән орлык бирү чыганакларын һәм плюс агачларын кисү һәм зарарлау тыела;<br>ж) рөхсәт ителгән чоры (рөхсәт ителгән кичектереп тору чорын да исәпкә алып) тәмамлангач агач материалы әзерләү, шулай ук файдалану хокукы туктатылгач яисә тәмамлангач агач материалы әзерләү рөхсәт ителми;<br>з) билгеләнгән вакытына (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) алып чыгылмаган агачны диләнкедә калдыру рөхсәт ителми;<br>и) урман үзләштерү проектында яисә диләнке ясауның технологик картасында каралмаган урыннарга агач материалын чыгару, тарттыру (транспорт белән күчерү) рөхсәт ителми;<br>к) диләнкене агач кисү калдыкларыннан (агачларны кисеп аударганда һәм тарттырганда (транспорт белән күчергәндә) диләнкедә барлыкка килә торган агач материалы калдыкларыннан, шулай ук кәүсәләрне киселгән агачларның очлык өлешләрен үз эченә алган ботаклардан, тамыр өсте өлешеннән, сабакларыннан, туздан) чистарту эшләрен үткәрмәү яки вакытында үткәрмәү рөхсәт ителми;<br>л) сөйрәмә җирләрдән һәм төяү мәйданнарыннан кала, туфракның өске уңдырышлы катламын юк итү рөхсәт ителми.<br>Диләнкеләрдә агач материалы әзерләгәндә яшәргә яраклы, аларның табигый ареалы чикләрендә үсеп китүче (әгәр тиешле агач токымының урманнар составындагы мәйданы өлеше урманчылык мәйданының 1 процентыннан артып китмәсә) кыйммәтле агач токымнарын (имән, бук, корычагач, эрбет, юкә, күг, элмә, кара зирек, чәчә торган каштан) кисү рөхсәт ителми.<br>Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән зат төрләре сакланырга тиешле.<br>Агач материалы әзерләгәндә урман утыртмалары агачлары составында 3 һәм аннан да күбрәк берәмлектә кедр катнашучы өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисү рөхсәт ителми. |
| 2. | Чәер әзерләү | Түбәндәгеләргә кирт салу тыела:<br>а) юкка чыгарганчыга кадәр зарарлы организм чыганакларында урнашкан урман утыртмаларына;<br>б) урман янгыннары, зарарлы организмнар һәм башка тискәре факторлар нәтиҗәсендә зарарланган һәм зәгыйфьләнгән урман утыртмаларына;<br>в) Россия Федерациясе законнары нигезендә агач әзерләү максатында өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын тоташ яки сайланма кисүләр рөхсәт ителмәгән урманнардагы урман утыртмаларына; |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | г) даими урман-орлык кишәрлекләрендә, урман-орлык плантацияләрендә, генетика резервацияләрендә урнашкан урман утыртмаларына, шулай ук плюс агачларына, орлыклыкларга, орлык чәчәклекләренә һәм полосаларына (Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 911 номерлы боерыгы белән расланган Чәер әзерләү кагыйдәләренең 7 пункты). |
| 3. | Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу | Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу өчен үсемлекләрнең түбәндәге төрләрен куллану тыела:<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрне;<br>- наркотик матдәләр дип таныла торганнарны;<br>- агачын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгәннәрне.<br>Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу чикләнергә яки радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә тыелырга мөмкин.<br>Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 496 номерлы боерыгы белән расланган Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю кагыйдәләренә ярашлы рәвештә:<br>- эрозиягә каршы урманнарда; су объектлары буйларында, чокыр сөзәклекләрендә урнашкан ярсаклагыч һәм туфраксаклагыч урман кишәрлекләрендә, фәнни яисә тарихи әһәмияткә ия урманнарда, шулай ук тулылыгы 0,8–1,0 тигез булган яшь агачларда һәм йомылмаган урман культураларында түмәр сагызын әзерләү рөхсәт ителми (13 пункт);<br>- агачларны туз әзерләү өчен кисү тыела (14 пункт);<br>- агач һәм куаклар кабыгын әзерләү рөхсәт ителми, әгәр бу эшчәнлек әзерләнгән урман продукциясенең сыйфатын киметүгә китерсә (15 пункт);<br>- чыбык-чабык әзерләгәндә агачларны һәм куакларны, аларның очларын, ботакларын һәм сабакларын, корткычларга һәм авыруларга бирешмәгән, кору билгеләре күзәтелмәгән агачларның очларыннан кисәргә рөхсәт ителми (16 нчы пункт);<br>- табигый һәм башка объектларны саклау функцияләрен башкаручы урманнарда, су саклау зоналарында урнашкан урманнарда кыйммәтле урманнарда түшәмәләрне җыю тыела (21 пункт);<br>- сынау һәм эксперименталь кисүләр үткәргәндә, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урманнарда даими сынау мәйданнарында себерке һәм үрү өчен себеркеләр, ботаклар һәм куаклар, модель агачларын сайлап алу рөхсәт ителми (23 пункт);<br>- сынау һәм эксперименталь кисүләр үткәргәндә агач яшеллеген әзерләү, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирелгән урманнарда даими сынау |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | мәйданнарында модель агачларын сайлап алу рөхсәт ителми (24 пункт). |
| 4. | Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю | Төрләре Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән яки наркотик матдәләр булып саналган гөмбәләрне һәм кыргый үсүче үсемлекләрне әзерләү һәм җыеп алу рөхсәт ителми.<br>Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнергә мөмкин.<br>Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 494 номерлы боерыгы белән расланган Азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыю кагыйдәләрен раслау кагыйдәләренә ярашлы рәвештә:<br>- җимеш бирә торган агачларны кисү һәм җимешләр әзерләү өчен ботакларны кискәләү тыела (13 пункт);<br>- чикләвекләрне әзерләгәндә агачларны һәм куакларны кисү, шулай ук агачларга һәм куакларга зыян сала торган ысулларны куллану тыела (14 пункт);<br>- гөмбәләр әзерләү аларның ресурсларын саклауны тәэмин итүче ысуллар белән башкарылырга тиеш (15 пункт);<br>- каен суты әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәренә кимендә 5 ел калгач рөхсәт ителә (16 пункт);<br>- башка төрле азык-төлек ресурслары әзерләү аларның үрентеләре торышына зыян салмый торган ысуллар белән башкарылырга тиеш; үсемлекләрне тамырлары белән өзеп алырга, яфракларына (ботакларына) һәм тамырларына зыян салырга рөхсәт ителми (17 пункт). |
| 5. | Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру | Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру тыела:<br>- урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда (РФ Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешендәге 2 пункты).<br>- шәһәр урманнарында (РФ Урман кодексының 116 статьясының 2 өлеше 2 пункты)<br>- яшел зоналарда урнашкан урманнарда, әгәр күрсәтелгән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру урман утыртмаларын кисүгә яки аучылык инфраструктурасы объектларын булдыруга китерсә (РФ Урман кодексының 114 статьясының 4 өлешендәге 4 пункты). |
| 6. | Авыл хуҗалыгы алып бару | Су саклау зоналарында урнашкан урманнарда авыл хуҗалыгы алып бару тыела, печән чабу, умартачылык һәм товар аквакультурасыннан (товар өчен балыкчылыктан) тыш (РФ Урман кодексының 113 статьясының 2 пункты).<br>Саклагыч урманнарның яр буе чикләрендәге җирләрне сөрү, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү һәм алар өчен җәйге лагерьлар, ванналар оештыру тыела (РФ Су кодексының 65 статьясының 17 өлешендәге 1, 3 пунктлары).<br>Урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда авыл хуҗалыгы алып бару тыела (РФ Урман кодексының 114 статьясының 2 |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | өлешендәге 3 пункты).<br>Яшел зоналарда урнашкан урманнарда, печән чабу һәм умартачылыктан, шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында киртәләп алулардан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (РФ Урман кодексының 114 статьясының 4 өлешендәге 2 пункты).<br>Шәһәр урманнарында авыл хуҗалыгы алып бару тыела (РФ Урман кодексының 116 статьясының 2 өлешендәге 3 пункты).<br>Тыюлыклы урман участокларында авыл хуҗалыгын алып бару тыела (РФ Урман кодексының 119 статьясының 3 өлешендәге 3 пункты).<br>Махсус саклана торган урман кишәрлекләрендә, печән чабудан һәм умартачылыктан кала, авыл хуҗалыгын алып бару тыела (РФ Урман кодексының 119 статьясының 4 өлешенең 2 пункты).<br>Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә генә урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 2 июлендәге 408 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә генә урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>- урман культуралары, кыйммәтле агач токымнарының табигый яшь агачлары, үсеш алган яшъ үсентеләр биләгән җирләрдә авыл хуҗалыгы хайваннарын көтүгә юл куелмый;<br>- селекция-урман орлыклары, имән, чыршы-пихта, тал, яфраклы каты, чикләвекле плантацияләр үсә торган кишәрлелкәрдә авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү рөхсәт ителми;<br>- урманнарны табигый торгызуга һәм ылыслы һәм яфраклы каты токымнар белән урманнарны торгызуга ярдәм итү буенча проектлана торган чаралар булган кишәрлекләрдә авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү;<br>- җиңел юыла торган һәм җилләтелә торган туфраклы кишәрлекләрдә авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү.<br>Урманнарны авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдалану максатында урманнарны табигый торгызу һәм ылыслы һәм яфраклы каты токымнар, җиңел юыла һәм җилләтелә торган туфраклар белән торгызуга ярдәм итү буенча проектланган чаралар белән урман культуралары, кыйммәтле агач токымнарының табигый яшь үсентеләре, селекция-урман орлыклары, каен-пихта, тал, яфраклы каты, чикләвек плантацияләре биләгән урман фонды җирләрен куллану тыела.<br>Авыл хуҗалыгы хайваннарын көткәндә (коймаланган урыннарда яки бәйдә тотып көтүдән тыш) урман культураларын, питомникларны, табигый шытып чыккан яшь үсентеләрне һәм урманның башка кыйммәтле кишәрлекләрен бозуга юл куелмаска |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | тиеш. |
| 7. | Балыкчылыкны гамәлгә ашыру, һәвәскәрләрчә балык тотудан тыш | Балыкчылыкны гамәлгә ашырганда, һәвәскәрләрчә балык тотудан тыш, түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларына, үсемлекләр капламына һәм туфракка зыян салу;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм аның чикләрендәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату. |
| 8. | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Урманнарны фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, белем бирү эшчәнлеге өчен кулланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларына, үсемлекләр капламына һәм туфракка зыян салу;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм аның чикләрендәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату (Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 27 июлендәге 487 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләренең 9 пункты).<br>Агулы химик препаратлар куллану тыела (РФ Урман кодексының 112 статьясының 4 өлеше, 113 статьясының 1 өлеше, 114 статьясының 2 өлешнең 1 пункты, 4 өлешенең 1 пункты). |
| 9. | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә табигый ландшафтлар, хайваннар дөньясы объектлары, су объектлары сакланырга тиеш (РФ Урман кодексының 41 статьясындагы 6 өлеше).<br>Россия Табигать ресурслары министрлыгының «Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 908 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>- рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә табигый ландшафтлар, хайваннар дөньясына караган объектлар, үсемлекләр дөньясы, су объектлары сакланырга тиешле (4 пункт);<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына яки Россия Федерациясе субъекты кызыл китабына кертелгән сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, башка урман үсемлекләрен саклау мөмкин булмаган очракта, урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану рөхсәт ителми. (4 пункт); |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | - РФ Урман кодексының 41 статьясының 3 өлешендә күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашырганда физик затларның яшәү урыннары булган объектларны урнаштыру рөхсәт ителми (5 пункт);<br>- урманнардан рекреация эшчәнлеген алып бару өчен файдалану әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә зыян китерми торган ысуллар белән башкарыла (6 пункт). |
| 10. | Урман плантацияләре булдыру һәм аларны эксплуатацияләү | Урман плантацияләрен булдыру һәм аларны эксплуатацияләү максатларында урманнардан файдалану очрагында:<br>- су саклау зоналарында урнашкан урманнардан файдалану тыела (РФ Урман кодексының 113 статьясының 3 пункты);<br>- минус утыртмаларында плюс агачларын сайлау рөхсәт ителми. (Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман орлыкчылыгы объектларын (урман орлыкчылыгы плантацияләрен, даими урман орлыкчылыгы кишәрлекләрен һәм мондый объектларны) төзү һәм бүлеп бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 20 октябрендәге 438 номерлы боерыгы белән расланган Урман орлыкчылыгы объектларын (урман орлыкчылыгы плантацияләрен, даими урман орлыкчылыгы кишәрлекләрен һәм мондый объектларны) төзү һәм бүлеп бирү кагыйдәләренең 7 пункты). |
| 11. | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү | Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 июлендәге 497 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>- җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләр, шулай ук урманга әверелмәгән агачлар киселгән урыннар, аланнарны һәм аларга урман культураларын утырткaнчы урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман үсемлекләре белән капланмаган җирләр; рекультивацияләнергә тиешле (эшләнелгән торфлыклар) (11 пункт) җирләр файдаланыла;<br>- җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен – үстерү өчен үзгәртеп коруга билгеләнмәгән, азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин (12 пункт);<br>- РФ Урман кодексының 60.15 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләреннән җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану тыела. |
| 12. | Урман питомникларын булдыру һәм аларны эксплуатацияләү | Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман питомникларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 12 октябрендәге 737 номерлы боерыгы белән расланган Урман питомникларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү кагыйдәләре нигезендә: |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | - урман питомникларында кәлшәләр, чәчүлекләр үстерү өчен чәчүлек һәм башка төр үзенчәлекләре тикшерелмәгән урман үсемлекләре орлыкларын куллану рөхсәт ителми (9 пункт);<br>- урман питомникларында урман үсентеләре орлыклары партияләрен аерым чәчү кулланыла; урман үсемлекләре орлыклары партияләрен катнаштыру рөхсәт ителми (11 пункт);<br>- урман питомникларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү өчен урман белән капланмаган җирләр кулланыла (13 пункт);<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына яки Россия Федерациясе субъекты Кызыл китабына кертелгән сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, башка урман үсемлекләрен саклау мөмкин булмаган очракта, урман питомникларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану рөхсәт ителми (14 пункт);<br>- Россия Федерациясе Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен урман утыртмаларының утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану РФ Урман кодексының 60.15 статьясы нигезендә тыела. |
| 13. | Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне гамәлгә ашыру, файдалы казылмалар эзләү һәм чыгару | Яшел зоналарда урнашкан урманнарда һәм урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда файдалы казылмалар разведкалау һәм чыгару тыела (РФ Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешендәге 4 пункты, 4 өлешендәге 1 пункты).<br>Шәһәр урманнарында файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару тыела (РФ Урман кодексының 116 статьясының 2 өлешендәге 4 пункты).<br>Җир астын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару максатларында урманнардан файдалану рөхсәт ителми:<br>а) Урман кодексында билгеләнгән тәртиптә расланган Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре нигезендә агачларны кисеп аудару һәм бульдозерлар ярдәмендә агач үсемлекләреннән чистарту, чик буе полосаларын һәм урман кырыйларын кисү калдыклары белән чүпләү, урман кырыйларындагы агачларның ботакларына һәм скелет тамырларына зыян китерү, җәйге чорда яңа кисеп алынган агач материалын санитар куркынычсызлык кагыйдәләре нигезендә кәүсә корткычларына каршы саклык чараларын күрмичә урманда калдыру (саклау);<br>б) урман утыртмаларын суга батыру һәм озак итеп су бастыру;<br>в) урманнардан файдалану гамәлгә ашырыла торган җирләрдән читтә урман утыртмаларына, үсемлекләр япмасына һәм туфракка зыян китерү;<br>г) урманнарны җитештерү һәм куллану калдыклары белән чүпләү;<br>д) урманнардан һәм аның читендәге территорияләрдән файдалану гамәлгә ашырыла торган җирләрнең мәйданнарын химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>е) транспорт чараларының һәм башка механизмнарның ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буенча, шул исәптән урманнардан |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | файдалану гамәлгә ашырыла торган җирләрдән читтә йөрүе (Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен һәм урман кишәрлеген бирмичә, сервитут билгеләп яки билгеләмичә генә, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру максатларында урманнардан файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 7 июлендәге 417 номерлы боерыгы белән расланган Файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләренең һәм урман кишәрлеген бирмичә, сервитут билгеләп яки билгеләмичә генә, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгаруны гамәлгә ашыру максатларында урманнардан файдалану очраклары исемлегенең 18 пункты). |
| 14. | Сусаклагычлар һәм башка ясалма су объектларын төзү һәм эксплуатацияләү, диңгез һәм елга портларын төзү һәм киңәйтү, гидротехник корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү | Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү тыела (РФ Урман кодексының 119 статьясының 3 өлешендәге 5 пункты). |
| 14. | Линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, алардан файдалану | Урманнарны линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) аларда урманнардан файдалану гамәлгә ашырыла торган һәм линияле объектларның саклау зоналарындагы җирләрдән читтәге урман утыртмаларына, үсемлек капламына һәм туфракка зыян китерү;<br>б) урманнардан файдалану гамәлгә ашырыла торган җирләргә тоташкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш чүп-чары, агач калдыклары белән чүпләү;<br>в) урманнар файдаланыла торган җирләрне һәм урманнар файдаланыла торган җирләргә якын территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) транспорт чараларының, механизмнарның ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буенча үтүе (Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урманнардан линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки билгеләмичә урманнардан линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 10 июлендәге 434 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләренең һәм Урман кишәрлеген бирмичә, сервитут, гавами сервитут билгеләп яки |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | билгеләмичә урманнардан линияле объектларны төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү өчен файдалану очраклары исемлегенең 15 пункты).<br>Урман паркы зоналарында урнашкан урманнарда, велосипед һәм йөгерү юллары һәм гидротехник корылмалардан тыш, капиталь төзелеш объектларын төзү тыела (РФ Урман кодексының 114 статьясының 2 өлешендәге 5 пункты).<br>Яшел зоналарда урнашкан урманнарда капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү тыела, гидротехник корылмалардан, элемтә линияләреннән, электр тапшыру линияләреннән, җир асты үткәргечләреннән тыш (РФ Урман кодексының 114 статьясының 4 өлешендәге 3 пункты).<br>Шәһәр урманнарында капиталь төзелеш объектлары төзү тыела, велосипед һәм йөгерү юллары һәм гидротехник корылмалардан тыш (РФ Урман кодексының 116 статьясының 2 өлешендәге 5 пункты). |
| 15. | Агач эшкәртү инфраструктурасы объектларын төзү һәм эксплуатацияләү | Саклагыч урманнарда, шулай ук РФ Урман кодексында, башка федераль законнарда каралган башка очракларда (РФ Урман кодексының 14 статьясындагы 2 өлеше) урман эшкәртү инфраструктурасын булдыру һәм эксплуатацияләү тыела.<br>Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда түбәндәге очраклар булмаска тиеш:<br>- урманнарны пычрату (шул исәптән радиоактив һәм нефть матдәләре белән) һәм урманнарга башка төрле тискәре йогынты ясау;<br>- гражданнарның урманнарда булуына чикләүләр кертелгән очракта, транспорт чараларының урман кишәрлекләренә керүе (Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 31 гыйнварындагы 54 номерлы боерыгы белән расланган Урманнардан агач материалын һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләренең 6 пункты). |
| 16. | Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру | Капиталь булмаган корылмалар, урман инфраструктурасын булдыру белән бәйле булмаган корылмалар төзү өчен урман утыртмаларын тоташ кисү рөхсәт ителми, ә урманнардан файдаланганда РФ Урман кодексының 41 статьясына ярашлы рәвештә урман утыртмаларына сайланма кисүләр дә рөхсәт ителми.<br>Урманнардан файдаланганда федераль законнарга ярашлы рәвештә торак йортларга кертелгән капиталь төзелеш объектларын төзү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми.<br>Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен урманнарны тулаем кисү рөхсәт ителми.<br>Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә дини һәм хәйриячелек билгеләнешендәге биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне торгызу рөхсәт ителә. |

| Т/с | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдаланудагы чикләүләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | Кишәрлекне көнкүреш калдыклары белән чүпләү, ирекле маршрутлар буенча транспортта йөрү; урман утыртмаларына зыян китерү тыела. |

Гамәлдәге урман орлыкчылык объектларының нормативлары һәм параметрлары әлеге урман хуҗалыгы регламентында әзерләнми, урман орлыкчылык объектлары турында белешмәләр ел саен Россия Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Дәүләт урман реестрын алып бару формаларын раслау турында» 2021 елның 24 декабрендәге 1007 номерлы боерыгы белән расланган 14-ГЛР формасы буенча яңартыла.